**К. С. Фәтхуллова, Э. Н. Денмөхәммәтова**

# ТЕЛДӘН СӨЙЛӘМГӘ ӨЙРӘТҮ

КАЗАН
2015

# КЕРЕШ

Кулланма төп гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен үстерү һәм тикшерү максатыннан төзелде. Аның беренче бүлеге укучыларның монологик сөйләм күнекмәләрен камилләштерергә мөмкинлекләр бирә, чөнки укучылар тәкъдим ителгән тема һәм сораулар буенча аңлаешлы һәм эзлекле, шул ук вакытта интонацион һәм грамматик яктан дөрес, бәйләнешле сөйләм оештырырга күнегә алалар. Икенче бүлек укучыларның диалогик сөйләм күнекмәләрен ныгытуга юнәлтелгән. Алар, төрле ситуатив рольләрне башкарып, әңгәмә корырга, әңгәмәдәш белән сөйләшү үткәрергә, кирәкле мәгълүматны ачыкларга өйрәнәләр. Шушы максаттан чыгып, кулланмада "Татар теленнән үрнәк эш программасы"нда (төзүче-авторлары – Р.З.Хәйдәрова, К.С.Фәтхуллова, Г.Р.Әхмәтҗанова, 2013) күрсәтелгән темаларга бәйле монологик һәм диалогик текст үрнәкләре тупланды. Алар, беренчедән, укучыларның бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү һәм лексик-грамматик белемнәрен тирәнәйтүне, икенчедән, укучыларның көндәлек тормышы, уку һәм кызыксынулары, шулай ук республикабызның һәм башкалабызның тарихи һәм истәлекле урыннары, татар халкының күренекле шәхесләре турында хәбәр итәргә һәм фикер алышырга өйрәтүне үз эченә ала.

Монологик сөйләмгә өйрәтүне түбәндәгечә оештырырга мөмкин: бирем белән танышу; үрнәк тексттан файдаланып һәм биремдә күрсәтелгән сорауларны яктыртып сөйләү; темага бәйле өстәмә сорауларга киңәйтелгән җаваплар бирү. Төп гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаучы укучы 1,5-2 минутлык монолог сөйли белергә тиеш. Укучыларның монологик сөйләмен бәяләгәндә, укытучы коммуникатив максатка ирешүне; теманы тулысынча ачып бирүне; бәйләнешле сөйләмне лексик-грамматик яктан дөрес оештыруны исәпкә ала.

Диалогик сөйләмгә өйрәткәндә, укучылар бирелгән ситуация буенча әңгәмә корырга; сөйләшүне башлап һәм кирәк очракта җанландырып җибәреп, үзләрен кызыксындырган сорауларны бирергә һәм аларга җавап алырга; этикет үрнәкләрен урынлы кулланырга; актив һәм итагатьле әңгәмәдәш булырга күнегәләр. Төп гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаучы укучы, сөйләшү барышында 10 нан артык репликаны лексик-грамматик яктан дөрес формалаштырып, аралашу максатына ирешә белергә тиеш.

Кулланмада бирелгән монологик текстлар нигезендә темага бәйле яңа мәгълүмат табу; аралашу ситуацияләреннән чыгып, мөстәкыйль рәвештә проектлар төзеп яклау, презентацияләр әзерләү эшләре дә тәкъдим ителергә мөмкин. Барлык эш төрләре дә укучыларның телдән аралашу-аңлашу күнекмәләрен камилләштерүгә хезмәт итә.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК. МОНОЛОГИК СӨЙЛӘМГӘ ӨЙРӘТ

**Бирем.** Үзегез белән таныштырыгыз. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- укуыгыз һәм сыйныфташларыгыз;
- буш вакытыгызны үткәрү һәм мавыгуларыгыз;
- якын туганнарыгыз һәм аларның һөнәрләре.

### ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Минем исемем - ... . Миңа ... яшь. Мин — укучы. Хәзерге вакытта ... (Казан, Бөгелмә, Әлмәт һ.б.) шәһәренең ... нче мәктәбендә ... сыйныфта укыйм. Сыйныфыбыз бик тату. Сыйныфта без ... укучы. Сыйныфташларым – тырыш, тәртипле, ярдәмчел укучылар.

Мин ... шәһәрендә (авылында) , ... урамында, ... йортта, ... фатирда яшим.

Мин ... (тарих, әдәбият, телләр, рәсем, спорт, музыка, сәнгать) белән кызыксынам. Мин ... (русча, татарча, инглизчә, французча, алманча, төрекчә, испанча, гарәпчә) беләм.

Буш вакытымда ... (музыка тыңларга, китаплар укырга, спорт белән шөгыльләнергә, компьютерда уйнарга) яратам.

Гаиләбездә ... (ике, өч, дүрт, биш) кеше. Бу — әтием, әнием, ... (абыем, апам, энем, сеңлем) һәм мин. Әниемнең исеме — ... . Ул — ... (укытучы, тәрбияче, хисапчы, табибә, хуҗабикә). Әтиемнең исеме — ... . Ул — ... (эшмәкәр, эшче, төзүче, табиб, тәрҗемәче). Абыемның (апамның, энемнең, сеңлемнең) исеме — ... . Ул — ... (укучы, студент, аспирант). Гаиләбез бик тату.

Безнең туганнарыбыз күп. Алар ... (Казанда, Яр Чаллыда, Мәскәүдә, Алабугада, Санкт-Петербургта, Пермьдә, Саратовта) яшиләр.

**Сораулар**

Мәктәптә Сезгә кайсы фән күбрәк ошый һәм ни өчен?
Сез инглиз телен ничә ел өйрәнәсез?
Туганнарыгыз белән еш очрашасызмы?

**Бирем.** Дусларыгыз белән таныштырыгыз. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- якын дусларыгызның исемнәре;
- аларның укулары һәм хыяллары;
- дусларыгыз белән ничек таныштыгыз.

### ДУСЛАРЫМ ТУРЫНДА

Минем өч дустым бар. Беренчесе — Азат, икенчесе — Денис, өченчесе — Алсу. Алар өчесе дә — минем сыйныфташларым. Без — беренче сыйныфтан бирле дуслар. Без мәктәпкә әзерлек курсларында танышкан идек һәм хәзер һәрвакыт мәктәпкә бергә барабыз, мәктәптән дә бергә кайтабыз. Кичләрен дә бергә саф һавада йөрибез. Ял көннәрендә паркка, кафеларга барабыз.

Азат математика дәресләрен бик ярата. Ул «дүрт»ле-«биш»ле билгеләренә генә укый, төрле олимпиадаларда катнаша. Аның хәтта берничә Мактау грамотасы һәм дипломы бар. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Азат программист булырга хыяллана.

Денис тарих белән кызыксына. Ул бик күп укый, шуңа күрә күп белә. Денисның тарихчы буласы, археологик экспедицияләрдә катнашасы килә. Аның әтисе дә — тарихчы, университет профессоры. Аларның өендә дөнья тарихы, Россия тарихы буенча китаплар, кызыклы энциклопедияләр бик күп.

Алсу чит телләрне яхшы белә. Ул туган телендә дә, инглиз телендә бик яхшы сөйләшә, тагын испан теле белән дә кызыксына. Алсуның иң зур хыялы - тәрҗемәче булу. Аның төрле илләрдә буласы, төрле мәдәниятләрне өйрәнәсе килә.

Дусларым бик ярдәмчел, юмарт, максатчан. Мин аларны бик яратам. Алар белән аралашу бик күңелле.

**Сораулар**

Сезгә дусларыгызның нинди сыйфатлары ошый?
Син алар белән ничә ел дус?
Дуслык турында мәкальләр беләсезме?

**Бирем.** Мәктәбегез турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- мәктәптәге уку кабинетлары;
- мәктәп укучыларының уңышлары;
- мәктәп китапханәсе.

## МӘКТӘБЕМ ТУРЫНДА

Мин укый торган мәктәп яңа. Ул дүрт катлы, зур һәм бик матур.

Беренче катта ашханә, китапханә, актлар залы, спорт залы урнашкан. Икенче, өченче, дүртенче катларда сыйныф бүлмәләре. Алар якты һәм уңайлы.

Коридорлар иркен, тәрәзәләр  биек. Коридорларда гөлләр үсә, ял итү өчен утыргычлар куелган.

Мәктәптә бер меңнән артык укучы укый.  Укулар бер сменада бара. Мәктәптә төрле кабинетлар күп: рус теле һәм әдәбияты кабинеты, татар теле һәм әдәбияты кабинеты, математика, биология, физика, химия, география кабинетлары. Алар барысы да заманча җиһазландырылган.

Мәктәпнең спорт залы зур, матур. Анда физкультура дәресләре үтә. Залда укучылар волейбол, баскетбол уйныйлар. Безнең мәктәп укучылары төрле спорт ярышларында катнашалар һәм җиңү яулыйлар. Безнең сыйныф укучылары арасында мәктәп чемпионнары да бар: иң яхшы теннисчы һәм иң яхшы чаңгычы.

Мәктәбебездә төрле түгәрәкләр эшләп килә: шахмат түгәрәге; математика түгәрәге; хор түгәрәгере, гимнастика түгәрәге һәм башкалар.

Мәктәп китапханәсе бик бай. Без анда бик теләп йөрибез. Уку залында төрле кызыклы журналлар укыйбыз. Китапханәдә татарча китаплар да күп. Алар безгә татар телен өйрәнү өчен бик кирәк. Шул китаплардан файдаланып, без татар теле дәресләренә презентацияләр әзерлибез, проектлар төзибез, белемнәребезне арттырырга тырышабыз.

Мин мәктәбемне бик яратам.

**Сораулар**

Мәктәбегездә кайсы фәннәрне өйрәнүгә аерым игътибар бирелә?
Мәктәбегездә нинди кызыклы чаралар үткәрелә?
Мәктәпне икенче өй дип атарга мөмкинме?

**Бирем.** Үзегез яшәгән йорт һәм фатирны тасвирлагыз. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- фатирыгыздагы бүлмәләр;
- төрле бүлмәләрдәге җиһазлар;
- фатирыгызның сезгә ошавы-ошамавы.

## ЙОРТЫБЫЗ, ФАТИРЫБЫЗ

Безнең йортыбыз ... урамында урнашкан. Бу ... (биш, тугыз, унике) катлы ... (иске, яңа) йорт. Фатирыбыз ... (алтынчы, унынчы) катта урнашкан. Ул ... (бер, ике, өч) бүлмәле. Анда алгы бүлмә, аш бүлмәсе, кунак бүлмәсе, йокы бүлмәсе, балалар бүлмәсе, эш бүлмәсе, юыну бүлмәсе бар.

Алгы бүлмә кечкенә. Анда көзге, кием шкафы, аяк киеме киштәсе бар. Идәндә кечкенә палас ята. Аш бүлмәсе зур, якты һәм уңайлы. Анда аш өстәле, урындыклар, савыт-саба шкафы, газ плитәсе, суыткыч бар. Тәрәзәгә матур пәрдә эленгән. Тәрәзә төбендә гөлләр үсә.

Кунак бүлмәсендә журнал өстәле, диван, ике кәнәфи, китап шкафы тора. Идәнгә зур һәм йомшак келәм җәелгән. Диварга сәгать эленгән. Бу бүлмә бик иркен, бик матур.

Йокы бүлмәсендә җиһазлар күп түгел. Анда караватּ, кием шкафы, көзге һәм китап киштәләре бар.

Балалар бүлмәсендә карават, язу өстәле, урындык, китап шкафы бар. Язу өстәлендә компьютер һәм өстәл лампасы тора. Китап шкафында русча, татарча китаплар, төрле сүзлекләр, энциклопедияләр күп. Диварга фотолар һәм календарь эленгән.

Юыну бүлмәсендә көзге, юыну әйберләре киштәсе, кер юу машинасы бар.

Фатирыбыз миңа бик ошый.

**Сораулар**

Сез яши торган йорт янында нәрсәләр бар?

Сез бу йортта ничә ел яшисез?

Фатирыгыздагы җиһазларны яңартырга телисезме?

**Бирем.** Ел фасыллары турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- һәр ел фасылының матурлыгы;
- укучыларның җәйге каникулларын үткәрүе;
- яраткан ел фасылыгыз.

## ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ

Дүрт ел фасылы бар: кыш, яз, җәй, көз.

Кышын көннәр салкын була. Урамнарны кар күмә. Елгаларны боз каплый. Кышын балалар чанада, чаңгыда, тимераякта шуарга яраталар. Алар кар бабай ясыйлар, хоккей уйныйлар. Укучыларның, студентларның кышкы каникуллары була. Алар күңелле ял итәләр.

Кыштан соң яз килә. Язгы көннәр җылы, кояшлы була. Урамнарда кар эри, гөрләвекләр ага. Кайвакыт яңгырлар ява, күк күкри. Язын табигать матурлана. Җылы яклардан кошлар кайта. Урманнарда беренче чәчәкләр күренә.

Яздан соң җәй килә. Җәен көннәр эссе, аяз була. Җәй — ял вакыты. Укучыларның, студентларның каникуллары башлана. Алар спорт лагерьларында ял итәләр, башка шәһәрләргә, илләргә баралар. Җәен алар су керәләр, кояшта кызыналар, көймәдә йөриләр, волейбол, футбол уйныйлар.

Җәйдән соң көз килә. Көзен көннәр болытлы, яңгырлы була. Кошлар җылы якларга китәләр. Бакчаларда, кырларда уңыш җыялар. Көзен мәктәпләрдә,

училищеларда, техникумнарда, университетларда укулар башлана. Мин ... (*җәйне, көзне, кышны, язны*) яратам.

**Сораулар**

Сезнеңчә, күп кешеләр ни өчен җәйне ярата?
Кышкы һәм җәйге каникуллар Россиядә күпме дәвам итә?
Язгы көннәр көзге көннәрдән аерыламы?

**Бирем.** Яраткан бәйрәмнәрегез турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- күпчелек кешеләрнең иң яраткан бәйрәме;
- Яңа елны каршылау;
- хатын-кызларны һәм ир-атларны котлау.

## РОССИЯДӘ ҺӘМ ТАТАРСТАНДА БӘЙРӘМНӘР

Безнең илдә иң яраткан бәйрәмнәрнең берсе булып Яңа ел бәйрәме санала. Бу бәйрәмгә алдан ук әзерләнә башлыйлар: дусларга һәм туганнарга бүләкләр сатып алалар, чыршы бизиләр. Яңа ел — гаилә бәйрәме. 31 нче декабрь көнне төнге сәгать уникедә бөтен гаилә бәйрәм табынына җыела. Барысы да бер-берсен Яңа ел белән котлыйлар, бәхет телиләр. Ә аннан соң чыршы төбеннән һәркем үзенә бүләк таба. Төн буе һәр фатирда, һәр йортта музыка яңгырый, кешеләр урамнарга чыгалар, Кыш бабай һәм Кар кызы аларны Яңа ел белән котлыйлар.

Тагын иң күңелле бәйрәмнәрнең берсе — Халыкара хатын-кызлар көне. Россиядә барлык хатын-кызларны 8 нче мартта котлыйлар. Бу көнне аларга чәчәкләр бүләк итәләр, матур сүзләр әйтәләр, алар хөрмәтенә артистлар чыгыш ясый.

Ел саен 23 нче февраль көнне Россиядә Ватанны саклаучылар көне билгеләп үтелә. Бу көнне солдат һәм офицерларны гына түгел, барлык ир-атларны бәйрәм белән котлыйлар.

Июнь аенда Татарстанда татар халкының яраткан милли бәйрәме — Сабан туе була. Сабан туеның иң төп вакыйгасы — көрәш. Көрәштә җиңгән батырга тәкә һәм кыйммәтле бүләк бирәләр. Икенче зур ярыш – ат чабышы. Бу ярышта беренче килгән атның хуҗасына да зур бүләк бирәләр, ә атның муенына яулыклар, сөлгеләр бәйлиләр. Бәйрәм вакытында кызыклы уеннар, спорт ярышлары үткәрелә, артистлар концерт куялар.

**Сораулар**

Сез бәйрәмнәрдә кайда булырга яратасыз?
Дусларыгызны бәйрәм белән ничек котлыйсыз?
Башка халыкларның нинди милли бәйрәмнәрен беләсез?

**Бирем.** Кышкы каникул турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- кышкы ялда Чыршы бәйрәмен үткәрү;
- дуслар белән аралашу;
- спорт белән шөгыльләнү.

## КЫШКЫ ЯЛ

Кышкы ял икенче чирек тәмамлангач башлана. Ул Яңа ел бәйрәме белән бер вакытта була. Без мәктәптә Чыршы бәйрәме үткәрәбез. Анда Кыш бабай һәм Кар кызы килә. Алар төрле кызыклы уеннар, биюләр оештыралар. Барыбыз да күңел ачабыз, җырлыйбыз, биибез, ял итәбез. Кыш бабай безне бәйрәм белән котлый һәм бүләкләр бирә.

Кышкы каникул ике атна дәвам итә. Каникулда мин шәһәрдә (авылда) булырга яратам. Ял вакытында китаплар укыйм, телевизор карыйм, музыка тыңлыйм, компьютерда уйныйм. Каникулда шулай ук дусларым белән дә бик еш аралашам. Без шәһәрдәге чыршыларны карарга барабыз, ... (кафега, клубка, дискотекага, кинога) йөрибез. Шулай ук спорт белән дә шөгыльләнәм: чаңгыда, чанада шуам. Дусларым белән шугалакка барырга һәм тимераякта шуарга да яратам. Гадәттә, гыйнвар аенда көннәр салкын була. Шуңа да карамастан мин саф һавада йөрергә тырышам. Саф һавада йөрү сәламәтлек өчен бик файдалы.

Кышкы каникул бик тиз үтә, ләкин мин һәрвакыт бик канәгать калам.

**Сораулар**

Укучылар кышкы каникулда кайларда ял итә алалар?
Сезгә  кышкы спорт төрләреннән кайсылары ошый?
Кышын табигать нинди була?

**Бирем.** Җәйге каникул турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- авылда ял итү;
- диңгезгә бару;
- бакча эшләрендә ярдәм итү.

## ҖӘЙГЕ ЯЛ

Уку елы тәмамлангач, укучыларның җәйге ялы башлана. Җәй — елның иң җылы, иң матур вакыты, шуңа күрә каникул күңелле үтә.

Гадәттә, июнь аенда мин авылга кунакка кайтам. Анда әбием һәм бабам яши. Мин аларга булышам: су китерәм, бакчадагы яшелчәләргә су сибәм, чүп утыйм. Авылда минем дусларым күп. Без алар белән күлдә су коенабыз, көймәдә йөрибез, балык тотабыз. Кичләрен урамда төрле уеннар уйныйбыз. Еш кына урманга барабыз һәм анда җиләк-җимеш, гөмбә җыябыз. Мин авыл Сабан туенда булырга бик яратам. Миңа бигрәк тә милли уеннар ошый: багана башына менү, чүлмәк вату, капчык киеп йөгерү. Ат чабышын да карарга яратам. Үзем дә төрле уеннарда, спорт ярышларында катнашам.

Авылдан кайткач, мин әтием һәм әнием белән диңгезгә ял итәргә барам. Анда су керәм, кояшта кызынам, яңа дусларым белән аралашам, күңелле ял итәм.

Август аенда, гадәттә, мин бакчада ял итәм. Бу вакытта җиләк-җимеш һәм яшелчә күп була. Әти-әнигә бакча эшләрендә ярдәм итәм.

Җәйге каникулда яхшы ял иткәннән соң, 1 нче сентябрьдә, шатланып, мәктәпкә киләм.

**Сораулар**

Җәен көннәр нинди була?

Җәен кешеләр кайларга ял итәргә баралар?

Җәен спортның кайсы төрләре белән кайда шөгыльләнергә мөмкин?

**Бирем.** Көндәлек тормышыгыз турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- иртән мәктәпкә әзерләнү;
- мәктәптәге дәресләр;
- өй эшләрен әзерләү һәм ял итү.

## КӨНДӘЛЕК РЕЖИМ

Иртән торгач, мин юынам, ашыйм, киенәм һәм мәктәпкә китәм. Мәктәпкә килгәч, мин дусларым белән очрашам, һәм без бергә дәресләргә барабыз. Һәр көн 5—6 сәгать укыйбыз. Безнең тарих, рус теле, химия ... (биология, инглиз теле, әдәбият) дәресләре була. Дәресләр беткәч, мин китапханәгә керәм. Анда журналлар, газеталар укыйм, яңа китаплар белән танышам. Атнага ике тапкыр мин бию ... (волейбол, каратэ, тегү) түгәрәгенә йөрим.

Өйгә кайткач, мин ашыйм, эчәм һәм аннары ял итәм: телевизор карыйм, музыка тыңлыйм, дусларым белән телефоннан сөйләшәм. Ял иткәч, дәресләргә әзерләнәм: дәреслекләрне укыйм, математикадан мәсьәләләр чишәм, татар һәм инглиз телләреннән текстлар тәрҗемә итәм, тарихтан һәм әдәбияттан

рефератлар язам, Интернеттан кирәкле мәгълүматны эзлим һәм өйрәнәм. Өй эшләрен әзерләгәч, саф һавада йөрим, дусларым белән очрашам һәм аралашам. Кайбер көннәрне без бергәләп бассейнга яки спортзалга барабыз.

Ял көннәрендә мин күбрәк өйдә булам, эти-әнием белән төрле яңалыклар турында сөйләшергә яратам. Кайвакытта дусларым белән концертларга, дискотекаларга йөрим, спорт ярышларын да карарга яратам. Вакытымны файдалы һәм күңелле үткәрергә тырышам.

**Сораулар**

Уку көннәрен ничек үткәрәсез?
Әти-әниегезгә өй эшләрендә ничек ярдәм итәсез?
Ни өчен вакытның кадерен белергә кирәк?

**Бирем.** Сәламәтлекне саклау турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- дөрес туклану;
- гигиена таләпләрен үтәү;
- кышын һәм җәен чыныгу ысуллары.

## СӘЛАМӘТЛЕК — ЗУР БАЙЛЫК

Сәламәт булу өчен, һәркем тырышырга тиеш. Сәламәт булырга теләсәң, иң беренче чиратта, яхшы тукланырга кирәк. Ашый торган ризыкта витаминнар булуы бик мөһим. Шуңа күрә кешеләр ит тә, сөт ашамлыклары да, яшелчәләр дә, җиләк-җимеш тә ашарга тиеш. Ләкин һәр ризыкны норма белән генә ашау яхшы.

Көндәлек гигиена таләпләрен үтәү дә бик әһәмиятле: иртән физик күнегүләр ясарга, ашаганнан соң тешләрне чистартырга, өс һәм аяк киемнәренең чисталыгын сакларга, бүлмәне даими чиста тотарга һәм җилләтергә, атнага 2—3 тапкыр физкультура һәм спорт белән шөгыльләнергә, саф һавада күбрәк булырга кирәк. Үзеңне чыныктыру да мөһим эш булып санала. Мәсәлән, салкын су белән коену бик файдалы.

Кышын да, җәен дә көн саен саф һавада йөрү яки йөгерү кеше организмына файда китерә. Җәен су коенырга, йөзәргә, көймәдә йөрергә, урманга барырга, футбол яки бадминтон уйнарга мөмкин. Ә кышын тимераякта, чаңгыда, чанада шуу, хоккей уйнау бик файдалы.

Шуны да истә тотыгыз: сәламәтлегегезне сакларга теләсәгез, начар кешеләр белән аралашмаска, стрессларга бирешмәскә тырышыгыз.

Сәламәтлек — зур байлык ул. Сәламәт тәндә — сәламәт акыл, диләр.

**Сораулар**

Сәламәт булу өчен, кешеләр нәрсәләр белән шөгыльләнәләр?

Көндәлек гигиена таләпләрен үтәмәү нәрсәгә китерергә мөмкин?

Дәүләт кешеләрнең сәламәтлеген саклау турында ничек кайгырта?

**Бирем.** Телләр өйрәнү турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- мәктәптә телләр өйрәнү;
- татар теле дәресләре;
- телләр белүнең файдасы.

## ТЕЛЛӘР ӨЙРӘНҮ

Мәктәптә без төрле телләр өйрәнәбез: рус, татар (инглиз, француз, алман, гарәп, фарсы, төрек, испан) телләре. Миңа телләр өйрәнү бик ошый. Минемчә, телләр белү – зур байлык ул.

Татар теле дәресләрендә без татарча сөйләшәбез, монологлар сөйлибез, текстлар укыйбыз. Укытучы безгә төрле сораулар бирә, ә без җавап кайтарабыз. Һәр дәрестә диярлек без яңа сүзләр өйрәнәбез, алар белән җөмләләр төзибез, аларны кабатлыйбыз һәм истә калдырырга тырышабыз. Дәрестә без төрле ситуатив күнегүләр эшлибез, татарча аралашырга өйрәнәбез. Татар теле дәресләрендә без Татарстан Республикасының халыкара багланышлары, икътисады, туган ягыбызның табигате, Казанның истәлекле урыннары һәм башка темаларга бәйле нда мәгълүмат алабыз. Шулай ук татар халкының тарихы, әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте, күренекле шәхесләре турында текстлар укыйбыз һәм аларның эчтәлеге буенча фикер алышабыз, әңгәмә корабыз. Татар теле дәресләренә мин яратып йөрим, чөнки укытучыбыз безне үзара сөйләшергә һәм аңлашырга өйрәтә. Телләр белгән — илләр гизгән, диләр.

Татар теле — төрки телләрнең берсе. Төрки телләргә башкорт, казакъ, нугай, карачай, комык, үзбәк, төрек, кыргыз, хакас, тува, якут, уйгур, гагауз, азәрбайҗан һәм башка телләр керә.

Татар телендә 7 миллионга якын кеше сөйләшә. Татар теле әһәмияте ягыннан дөньяда 14 нче урында тора. Аны белсәң, утызлап телдә аралашырга мөмкин.

**Сораулар**

Сезнеңчә, дөньяда күпме тел исәпләнә?

Халыкара аралашу теле булып, кайсы тел санала?

Телләр белү ни өчен файдалы?

**Бирем.** Россиядә татар телен укыту тарихы турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- татар теленең башка төрки телләрне белү өчен ачкыч булуы;
- Казан гимназиясендә татар теле укыту;
- татар телен өйрәнү өчен әсбаплар.

## РОССИЯДӘ ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУ ТАРИХЫННАН

XVI—XVIII гасырларда Россиянең Урта Азия һәм Көнчыгыш дәүләтләре белән эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруда татарлар тылмач буларак зур ярдәм күрсәткәннәр. Татар теле башка төрки телләрне белү өчен ачкыч булган. Россиянең Һиндстан, Кытай, Иран һәм башка күп кенә илләр белән рәсми эш кәгазьләре татар телендә алып барылган. Шунлыктан Россиядәге башка төрки телләр арасында татар теленең дәрәҗәсе югарырак булган. Ә бу исә XVIII гасыр урталарында ук күп кенә уку йортларында татар телен укыта башлауга китергән.

1769 нчы елда, Елизавета Петровна кушуы буенча, Казандагы дворян һәм разночинец балалары өчен булган гимназиядә татар теле укытыла башлый. Екатерина II боерыгы белән гимназиянең беренче татар теле укытучысы итеп Сәгыйть Хәлфин билгеләнә. Гимназиядә татар телен укыту тәҗрибәсенә нигезләнеп, ул әлифба яза. Бу хезмәтне мәктәп укытучылары тикшерәләр һәм аңа югары бәя бирәләр. 1778 нче елда бу хезмәт Мәскәүдә басылып чыга. Татар басма әлифбасының тарихы шушы китаптан башлана.

XVIII гасыр ахырыннан башлап татар теле дәресләре Мәскәү университеты каршындагы Академик гимназиядә, Омскидагы Азия тылмачлар мәктәбендә, Тобольскидагы һәм башка берничә шәһәрдәге рухани семинарияләрдә дә алып барыла. 1812 нче елдан Казан университетында да татар теле укытыла башлый.

Татар теле дәресләрен бу уку йортларында күренекле тюркологлар алып барган. Мәсәлән, Казан университетында озак еллар татар телен Ибраһим Хәлфин укыткан. Оренбург Неплюев кадет корпусында Салихҗан Кукляшев, Мартиниан Иванов, Мирсалих Бекчуриннар хәрбиләргә татар телен өйрәткәннәр. Казан рухани академиясендә А.Троянский һәм Н.Ильминскийлар татар теле дәресләре алып барганнар. Алар дәреслекләр, сүзлекләр, үзөйрәткечләр, сөйләүлекләр дә төзегәннәр. Мәсәлән, Габдүш Ваһаповның «Самоучитель для русских по-татарски и для татар по-русски» исемле хезмәте беренче тапкыр 1864 нче елда басылып чыга һәм соңрак тагын 20 тапкыр нәшер ителә. Үзөйрәткечләрдән тыш, бу чорда Сәгыйть Хәлфиннең ике-томлык беренче «Русча-татарча сүзлеге», Ибраһим Хәлфиннең «Татар теленең әлифбасы һәм грамматикасы», Мартиниан Ивановның «Татар грамматикасы» һәм «Татар хрестоматиясе» кебек хезмәтләре дөнья күрә.

Татар телен өйрәтү һәм татар теле дәреслекләрен язу эше Октябрьдан соң да дәвам иткән. 1920—30 нчы елларда М.Корбангалиев йөздән артык дәреслек һәм методик кулланма язып бастыра.

**Сораулар**

Хәзерге вакытта Россиядә татар теле ничәнче урында тора?
Бүгенге көндә татар телен укыту өчен, нинди кулланмалар бар?
Сезнеңчә, татар телен өйрәнү авырмы?

**Бирем.** Татарстандагы югары уку йортларының берсе турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- Казанның иң борынгы югары уку йорты;
- бүгенге университет;
- студентларның тормышы.

## КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ

Казан университеты 1804 нче елда ачылган. Аның беренче ректоры И.Ф.Яковкин булган. Университетта төрле елларда атаклы галимнәр эшләгән: математик Н. Лобачевский, химиклар А.Бутлеров, Н.Зинин һәм Арбузовлар, географ И.Симонов, физик Е.Завойский, телчеләр А.Казем-Бек, Бодуэн де Куртенэ, Хәлфиннәр, М.Корбангалиев һәм башкалар. Казан университетында зур фәнни ачышлар ясалган: Н.Лобачевскийның неевклид геометриясе, А.Бутлеровның органик кушылмалар теориясе, Е.Завойскийның электрон парамагнит резонансы. Лингвистларның һәм тюркологларның Казан мәктәпләре дә бөтен дөньяда танылу алган.

Бүгенге көндә дә университет галимнәре фәнгә зур өлеш кертәләр. Хәзерге вакытта Казан Идел буе федераль университетында 20 гә якын институт һәм факультет эшләп килә, аларда 40 меңнән артык студент белем ала. Алар арасында Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты, Фундаменталь медицина һәм биология институты һ.б. Минем киләчәктә КФУ ның Химия институтына укырга керәсем килә, чөнки әти-әнием кебек химик булырга телим.

Казан университеты студентлары фәнни эшләр белән шөгыльләнәләр, курс эшләре язалар. Алар фәнни хезмәтләр белән танышалар, тикшеренүләр үткәрәләр, фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашалар, чыгыш ясыйлар.

Ял вакытында студентлар походларга йөриләр, фестивальләр, концертлар, кичәләр оештыралар, спорт ярышларында катнашалар. Студентларның тормышы бик кызыклы.

Казан университеты — республикабызның, шәһәребезнең горурлыгы. Ул — Россиянең иң борынгы университетларыннан берсе.

**Сораулар**

Татарстанда иң танылган югары уку йортлары ниндиләр?
Казан федераль университеты кайда урнашкан?
Сез кайда югары белем алырга телисез һәм ни өчен?

**Бирем.** Татарстанның танылган югары уку йортлары турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- танылган югары уку йортлары;
- югары уку йортларының укытучылары;
- уку формалары.

## ТАТАРСТАННЫҢ ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫ

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында 20 дән артык дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган югары уку йорты исәпләнә. Алар арасында Казан федераль университеты, А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты һәм Казан милли тикшеренү технологик университеты, Казан дәүләт аграр университеты, Казан дәүләт медицина университеты, Казан дәүләт энергетика университеты, Казан дәүләт мәдәният университеты, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерватириясе һәм башкалар. Бу югары уку йортларында тәҗрибәле профессорлар, үз эшләрен яратучы белгечләр эшли. Алар студентларга сайлаган һөнәрләре буенча тирән белем бирәләр, яңа мәгълүмат җиткерәләр, тәҗрибәләре белән уртаклашалар.

Дәүләтнеке булмаган югары уку йортларында уку түләүле, шуңа да карамастан аларда меңләгән студент белем ала. Бу югары уку йортлары яңа икътисади шартлар өчен кирәкле булган белгечләр әзерли.

Югары уку йортларында, гадәттә, өч төрле уку формасы бар: көндезге бүлек, читтән торып уку бүлеге һәм кичке уку бүлеге. Аларда бюджет хисабына һәм түләүле уку системалары яшәп килә.

Болардан тыш, Татарстанның төрле шәһәрләрендә дә берничә югары уку йорты эшли. Алар арасында КФУ ның Алабуга Яр Чаллы һәм Чистай Институтлары, Әлмәт дәүләт нефть институты һәм башкалар.

Татарстанның югары уку йортларында Россиянең башка төбәкләреннән дә, чит илләрдән дә студентлар укый. Мәсәлән, Кытайдан, Төркиядән, Германиядән, Финляндиядән һ.б. Татартсан студентлары халыкара олимпиадаларда катнашалар һәм җиңүләр яулыйлар, фәнни конференцияләрдә чыгыш ясыйлар, спорт ярышларында яхшы нәтиҗәләр күрсәтәләр.

Күптән түгел Татарстанда иң заманча югары уку йорты - Иннополис ачылды.

**Сораулар**

Татарстан югары уку йортлары арасында иң популярлары нindиләр?

Казаннан тыш, Татарстанның кайсы шәһәрләрендә югары белем алырга мөмкин?

Сезнең кайсы югары уку йортында укыйсыгыз килә һәм ни өчен?

**Бирем.** Татарстанның башкаласы турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары;
- башкалада җитештерелә торган товарлар;
- башкаланың фәнни һәм мәдәни казанышлары.

## КАЗАН — ТАТАРСТАННЫҢ БАШКАЛАСЫ

Казан — борынгы шәһәр. Ул Иделнең сул ярында урнашкан. Казанның мәйданы — 288 кв. км. Анда 1 миллионнан артык кеше яши.

Казанның үзәгендә тарихи һәйкәл — Кремль балкып тора. Биредә Президент Сарае, Сөембикә манарасы, Кол Шәриф мәчете, Благовещение соборы урнашкан. Кремль каршындагы мәйданда герой-шагыйрь Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренә һәйкәл куелган.

Казандагы иң матур биналарның берсендә Татарстан Республикасының Милли китапханәсе урнашкан. Аның каршында — 1804 нче елда төзелгән мәшһүр Казан университеты. Биредә бөек ачышлар ясалган, атаклы галимнәр эшләгән. Университет — Казанның горурлыгы. Башкалабызда берсеннән-берсе матур биналар, урамнар, истәлекле урыннар шактый күп. Алар арасында Дәүләт музее, Сынлы сәнгать музее, шәһәр хакимияте бинасы, опера һәм балет театры һәм башкалар.

Казан — эре промышленность үзәге. Биредә самолетлар, вертолетлар, медицина җиһазлары, магнитлы тасмалар, мех һәм тегү әйберләре, дарулар һәм башка югары сыйфатлы товарлар житештерелә. Казанда эшләнгән әйберләр

төрле республикаларга, Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләренә, чит илләргә чыгарыла.

Казан — фән патшалыгы. Биредә Россия Фәннәр академиясенең Казан филиалы, Татарстан Фәннәр академиясе, фәнни-тикшеренү институтлары, югары уку йортлары урнашкан. Бу югары уку йортлары, шулай ук театр, музыка училищелары Идел буе һәм илебезнең башка төбәкләре өчен белгечләр әзерлиләр.

Казан — танылган мәдәни үзәк. Шәһәрдә 7 театр эшли: М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет академия театры, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, В. Качалов исемендәге Зур рус драма академия театры, К. Тинчурин исемендәге Татар драма һәм комедия театры, Яшь тамашачы театры, Г.Кариев исемендәге Татар яшьләр театры, “Әкият” Курчак театры. Биредә С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе, «Казан» милли мәдәният үзәге, спорт сарайлары, китапханәләр эшли.

2005 нче елда Казан тантаналы төстә үзенең меңьеллыгын бәйрәм итте. Меңьеллык уңаеннан Казанда яңа мәйданнар һәм һәйкәлләр ачылды: Меңьеллык паркы, Кол Гали һәм Лев Гумилев һәйкәлләре һ.б.

Бүгенге Казан зур, матур, мәһабәт.

**Сораулар**

Казанның кайсы тарихи урыннары сезгә ошый?
Туристлар ни өчен башкалабызга килергә яраталар?
Казан театрларында булдыгызмы?

**Бирем.** Казанның тарихы турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- Казан ханлыгының үзәге;
- Казан губернасының үзәге;
- шәһәр белән бәйле данлы исемнәр.

## КАЗАН ШӘҺӘРЕ ТАРИХЫННАН

Казанның ерак гасырлардан килгән зур тарихы бар. Казан каласы 1445 нче елда Казан ханлыгының үзәгенә әверелә. Ул заманда Казан Көнбатышның һәм Шәрыкның зур дәүләтләре, шәһәрләре белән элемтәдә торган. Үзенең таш пулатлары, мәчет манаралары, шәһәр ныгытмалары, имән капкалары беләнерактан ук күренеп торган.

Россия империясе составына кертелгәч, Казан зур бер губернаның башкаласына әверелә. Үз гомерендә аңа бик күп гыйбрәтле хәлләр күрергә туры

килә. Әллә ничә тапкыр янгын чыгып, яртысына кадәр янып бетә, ләкин кабат торгызыла...

1804 нче елда төзелгән мәшһүр Казан университеты шәһәрнең данын нык күтәрә. Анда математика, химия, тарихны өйрәнү фәннәре буенча бөек ачышлар ясала. Н. Лобачевский, Н. Зинин, А. Бутлеров, К. Фукс, Хәлфиннәр, А. Казем-Бек һәм Ш. Мәрҗаниләрнең фәнгә керткән зур өлешләре — Казан шәһәренең горурлыгы.

Шәһәр күп данлы исемнәр белән бәйләнгән. Емельян Пугачев үзенең гаскәрләре белән Казанны камаган. Аның «бунты» тарихын өйрәнү максатыннан, биредә А. С. Пушкин булган. Яшь граф Лев Толстой университетта укыган, бөек рус язучысы М. Горький үзенең «университетларын» шушы шәһәрдә узган... Исемнәрне саный китсәң, әлбәттә, дөнья культурасының бөек талантларын — Державин һәм Шаляпин, татар мәдәниятенең якты йолдызларын — Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов исемнәрен әйтми мөмкин түгел. Әдипләр, композиторлар, рәссамнар, артистлар: Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин, Муса Җәлил, Нәҗип Җиһанов, Бакый Урманче, Рөстәм Яхин, Әмирхан Еники, Илһам Шакиров... Болар һәммәсе — дөнья мәдәниятенә Казан шәһәре биргән бөек талантлар ...

«И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!» Бу сүзләрне татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай әйткән *(Р. Фәхретдиновтан)*.

**Сораулар**

Хәзерге Казан борынгы Казаннан кайсы яклары белән аерыла?

Казан тарихы турында нәрсәләр укыганыгыз бар?

Казанда яшәгән күренекле шәхесләрдән кемнәрнең исемнәре белән Казан урамнары аталган?

**Бирем.** Казанның төп истәлекле урыны – Кремль турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- Кремльнең тарихы;
- Сөембикә манарасы;
- Спас манарасы.

## КАЗАН КРЕМЛЕ

Казан — Татарстанның гына түгел, бөтен дөньяга таралган татар халкының башкаласы, рухи мәркәзе. Казан — Европа һәм Азия мәдәниятен тоташтыручы үзәк. Ул — кабатланмас тарихи һәйкәлләргә бай шәһәр. Башкаланың үзәгендә, Казансу елгасы ярында Кремль урнашкан.

Казан Кремле турында XVI гасырда ук тарихчылар сокланып язганнар. Аның эчендә таштан эшләнгән хан сарайлары һәм мәчетләр булган. Хәзерге Татарстан Республикасы Президенты резиденциясе урынында элек хан сарае булган. Сарай каршындагы зур мәйданда биек каравыл манарасы торган. Иң гүзәл архитектура һәйкәле — Сөембикә манарасы да күзәтү урынына охшаган. Кызыл кирпечтән салынган бу манара җиде катлы. Аның өч каты — дүрткырлы, ә калганнары сигезкырлы итеп эшләнгән. Манараның эчке ягында тар һәм текә баскычлар ясалган.

Кремльдә тагын бер гүзәл манара — Спас манарасы бар. Ул XVI гасырда төзелгән, ә XVIII гасырда аңа сәгать урнаштырылган. Элегрәк Кремльдән төрле якларга чыга торган 13 капка булган, хәзер сигезе генә сакланган.

Казан кунаклары Сөембикә-ханбикә манарасы, Благовещение соборының матурлыгына сокланалар.

**Сораулар**

Казан Кремлендә булганыгыз бармы?
Андагы тарихи биналардан кайсылары сезгә күбрәк ошый?
Казанга килүче туристларны нәрсәләр кызыксындыра?

**Бирем.** Сөембикә манарасы турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- манараның төзелүе;
- тарихи һәйкәлнең стиле;
- Сөембикәнең теләге.

## СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ

Сөембикә манарасы! Бу корылма Казанның гына түгел, Татар иленең символына әверелде.

…1549 нчы елда Казан ханы Сафагәрәй үлә. Сафагәрәйнең хатыны Сөембикә кушуы буенча, хан кабере өстенә шушы манара салына. Ул бик тиз арада төзелә. Сөембикәне 1551 нче елда Мәскәүгә алып китәләр. Димәк, мәгълүматлар әлеге манараның 1549—1551 нче еллар арасында салынуы турында сөйлиләр.

1552 нче елда Сафагәрәй кабере аннан алына. Шуннан соң бу корылманы күзәтү манарасы итеп файдаланалар. Шул заманнар өчен ул бик мөһим стратегик урын була.

Һәйкәл көнчыгыш стилендә эшләнгән һәм борынгы культ корылмаларына охшаш: кисек пирамидалардан төзелгән; 7 катлы; иң югарысы — изге урын; төрле төсләргә буялган һәм төрле орнаментлы террасалар бар. Сөембикә

манарасының архитектура ягыннан тиңдәшләре Ыссык күл янындагы борынгы каберлектә бар. Алар XII—XIV гасырларда куелган.

Бу элементлар нәрсә турында сөйлиләр соң? Моңа җавапны мөселман мифологиясеннән табарга мөмкин: «Алла, катлам-катлам итеп, Җиде Күкне яраткан. Җиденче Күк өстендә Алла тәхете урнашкан…».

Җиде Күк! Җиде катлы манара! Сөембикә үзенең сөекле иренең мәңгелектә җиденче кат күккә күтәрелүен, җәннәттә булуын теләгән.

**Сораулар**

Сезнең Сөембикә манарасын күргәнегез бармы?
Сөембикә ханбикә турында нинди мәгълүматлар беләсез?
Сөембикә манарасына охшаган нинди һәйкәлләрне беләсез?

**Бирем.** Татарстан Республикасы турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- республиканың урнашу урыны, халкы, зур шәһәрләре һәм елгалары;
- Татарстанда җитештерелә торган товарлар;
- Татарстанның башка илләр белән багланышлары.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Татарстан Идел буенда урнашкан. Аның мәйданы — 68 мең кв. км. Халкы — 3 миллион 700 мең кеше. Татарстанда 100 дән артык милләт вәкиле яши. Татарстан Республикасы составында 43 район, 19 шәһәр, шәһәр төрендәге 21 бистә һәм 3000 гә якын авыл исәпләнә. Иң зур шәһәрләр — Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Чистай, Алабуга һәм башкалар. Татарстан аша 4 зур елга ага: Идел, Кама, Нократ, Агыйдел. Кечкенә елгалар һәм күлләр дә күп.

Татарстан — эре промышленность үзәге. Казан шәһәрендә самолетлар, вертолетлар, медицина җиһазлары, мех һәм тегү әйберләре житештерелә. Чаллыда — «КамАЗ» йөк автомобильләре, Түбән Камада — синтетик каучук һәм автомобиль шиннары, Яшел Үзәндә суыткычлар эшләнә. Татарстанда эшләнгән югары сыйфатлы товарлар төрле республикаларга, БДБ илләренә, чит илләргә чыгарыла. Республикабызга да әлеге дәүләтләрдән төрле товарлар кертелә: авыл хуҗалыгы машиналары, минераль ашламалар, төзелеш һәм юл техникасы, агач материаллары.

Соңгы елларда Татарстан Россия Федерациясенең өлкәләре, БДБ илләре, Балтыйк буе илләре һәм күп кенә чит илләр белән ике яклы килешүләр төзеде һәм ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштырды. Татарстан көнчыгыш илләре белән дә, көнбатыш илләре белән дә багланышларны киңәйтә. Чит илләрдә Татарстанның вәкаләтле вәкиллекләре эшли. Алар чит ил кешеләренә Татарстан турында тулы мәгълүмат җиткерәләр.

Республикабызда дөньякүләм танылган театрлар, музейлар, югары уку йортлары эшли. Биредә ел саен Рудольф Нуриев исемендәге халыкара балет фестивале, Федор Шаляпин исемендәге халыкара опера фестивале, халыкара мөселман фильмнары фестивале үткәрелә.

Бүгенге көндә Татарстан — икътисади, фәнни, мәдәни үзәк.

**Сораулар**

Хәзерге вакытта Татарстан ни өчен алдынгы төбәкләрдән санала?
Татарстанның кайсы шәһәрләрендә булганыгыз бар?
Татарстан турында чит илләрдә беләләрме?

**Бирем.** Татарстан Республикасының табигате турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- Татарстан урманнарындагы үсемлекләр һәм хайваннар;
- зур елгалар һәм күлләр;
- иген үстерү һәм терлек үрчетү.

## ТАТАРСТАННЫҢ ТАБИГАТЕ

Татарстанның табигате матур, бай, серле һәм төрле. Калын зур урманнар да, тигез далалар да бар анда. Урманнарда төрле агачлар үсә, шуңа күрә катнаш урманнар да, ылыслы урманнар да шактый. Алар арасында наратлар, имәннәр, каеннар, юкәләр, чыршы агачлары да бар. Куе агачлар арасында, куаклыкларда пошилар, аюлар, бурсыклар, бүреләрне очратасың. Кызыл туннлы төлкеләр, куркак куяннар да еш очрый.

Татарстан Республикасын «дүрт елга иле» дип йөрткәннәр. Аның аша Идел, Чулман (Кама), Агыйдел, Нократ (Вятка) елгалары ага. Ык, Зәй, Мишә, Чирмешән, Зөя, Казансу елгалары исә — аларның кушылдыклары. Кечкенә елгалар, күлләр дә күп анда. Аккош күле, Кабан күле, Зәңгәр күл, Тирән күл һәм башка бик күпләр безнең республикабызда урнашкан. Алар бик уңайлы ял итү урыннары булып тора.

Татарстанның климаты уртача: кышлары артык салкын түгел, ә җәйләре түзә алмаслык эссе булмый. Шуңа күрә республиканың бай табигате, йомшак, саф һавасы иген үстерергә, терлек үрчетергә уңайлы. Болын-кырларда аллы-гөлле чәчәкләр, шифалы үләннәр бик күп. Татарстан кырларында бодай, кукуруз, карабодай, борчак, чөгендер, көнбагыш үстерәләр. Терлекчеләр мөгезле эре терлек үрчетәләр, кошчылык белән шөгыльләнәләр. Идел һәм Чулман буенда өлгергән алма, чия, кура җиләге, чикләвек тирә-якта иң тәмлеләрдән санала.

**Сораулар**

Татарстанның урманнарында булганыгыз бармы?

Сез табигатьтә ничек ял итәсез?
Сезгә Татарстанның табигате ошыймы?

**Бирем.** Табигатне саклау турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:
- табигатьне саклау проблемалары;
- Җир шарының киләчәге;
- табигатьне ярату.

ТАБИГАТЬНЕ САКЛАУ

Хәзерге вакытта табигатьне саклау проблемасы аеруча мөһимнәрдән санала. Моның сәбәпләре бик күп. Беренчедән, төрле радиоактив матдәләр җирләребезне, суларыбызны, һаваны агулый. Икенчедән, казылма байлыклар, агачлар елдан-ел азая. Өченчедән, иген уңышын арттыру өчен, бик күп химик ашламалар кулланыла. Шулай итеп, Җир нык зарарлана. Аның иксез-чиксез байлыклары агулана.

XXI гасырда Җир нинди булыр?

Җир шарының нинди булуы безгә бәйле, чөнки Җирдә без яшибез. Киләчәк еллар турында без хәзер кайгыртырга тиеш.

Кеше табигатькә зыян китергән икән, димәк, ул үзенә дә зарар китергән. Кеше үзе дә табигать баласы бит. Шуңа күрә һәр кеше табигатьне яратырга, аны саклау өчен көрәшергә тиеш. Табигать үзен яраткан кешеләрне генә ярата!

Чиста табигать — сәламәтлек нигезе. Шуңа күрә аны карап, чистартып торырга кирәк. Табигатьне саклау — Ватанны саклау дигән сүз ул!

**Сораулар**

Хәзерге вакытта иң мөһим экологик проблемалар нинди ләр?
Табигать алдында кем җаваплы?
Табигатьне саклау өчен, һәр кеше нишләргә тиеш?

**Бирем.** Татарстанның дәүләт символлары турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:
- дәүләт флагындагы төсләрнең мәгънәсе;
- дәүләт гербындагы сурәтнең мәгънәсе;
- дәүләт гимнын башкару урыннары.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ СИМВОЛЛАРЫ

Дөньяда 200 дән артык бәйсез дәүләт исәпләнә. Һәр дәүләтнең үз символлары була: флаг, герб һәм гимн.

Татарстанның Дәүләт флагы өч өлештән тора: өске өлеше — яшел, аскы өлеше — кызыл, ә уртада тар гына ак тасма сузылган. Һәр төснең үз мәгънәсе бар. Кызыл төс — кояш, ут төсе. Яшел төс — туган җиребезнең һәм табигатебезнең матурлыгы төсе, яшәү билгесе. Ак төс — намус, тынычлык-иминлек билгесе. Татарстанның Дәүләт флагы 1991 нче елда кабул ителде. Аның авторы — халык рәссамы Тавил Хаҗиәхмәтов.

Татарстанның Дәүләт гербында канатлы ак барс сурәтләнгән. Барс халыкның көчен белдерә. Аның тырнаклары һәм тешләре үткен, ә уң аягы бераз күтәрелгән. Димәк, ул һәркемне яклый ала. Барсның ян-ягында түгәрәк калкан урнашкан. Аңа кашкарый чәчәге төшерелгән. Калкан иминлекне белдерә, ә чәчәк — озын гомер билгесе. Яшел бөжра эчендә татар орнаменты чигелгән. Аста «Татарстан» сүзе язылган. Кызыл, ак, яшел төсләр — дәүләт флагы төсләре. Барс артындагы кояш аяз күкне, яктылыкны аңлата. Татарстанның Дәүләт гербы 1992 нче елда кабул ителде. Аның авторлары — рәссам Риф Фәхретдинов һәм галим Назыйм Ханзафаров.

Татарстанның Дәүләт гимны 1993 нче елда кабул ителде. Ул күренекле татар композиторы Рөстәм Яхин музыкасына язылган. Гимн бәйрәмнәрдә, тантаналы мизгелләрдә яңгырый.

Татарстан халыклары дәүләт символларын хөрмәт итәргә һәм аларны сакларга тиеш. Бу — аларның изге бурычы.

**Сораулар**

Татарстанның Дәүләт символларын кайларда күрергә мөмкин?
Сезнеңчә, дәүләт гербында ни өчен ак барс сурәтләнгән?
Татарстан Дәүләт гимнының сүзләрен беләсезме?

**Бирем.** Татарстанның вәкаләтле вәкилләре турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- Мәскәүдәге вәкиллекнең ачылуы;
- Мәскәүдәге татар оешмалары;
- вәкаләтле вәкиллекнең татар оешмалары белән бәйләнеше.

## ТАТАРСТАННЫҢ ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛЛЕКЛӘРЕ

Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең өлкәләре, БДБ илләре, көнчыгыш һәм көнбатыш дәүләтләре белән элемтәләрне киңәйтә. Чит илләрдә Татарстанның вәкаләтле вәкиллекләре эшли. Хәзерге вакытта Татарстанның уннан артык вәкиллеге бар.

Мәскәү — Россия Федерациясенең башкаласы, дөньякүләм билгеле иң зур шәһәрләрнең берсе. Анда чит ил вәкиллекләре һәм илчелекләре бик күп. Татарстанның Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиллеге 1994 нче елда ачылды. Чит ил эшкуарлары, сәясәтчеләр, мәдәният һәм фән эшлеклеләре вәкиллеккә төрле сораулар белән мөрәҗәгать итәләр.

Вәкиллек Россия өлкәләре белән дә бәйләнешләрне ныгыта. Мәскәүдә 800 меңгә якын татар яши. Шуңа күрә Мәскәүнең татар иҗтимагый тормышы да вәкиллек белән бәйләнгән. 1941 нче елга кадәр Мәскәүдә татар милли үзәге булган. Әле 1913 нче елда ук танылган эшкуар Шәмси Әсәдуллаев ярдәмендә, халык акчасына татар мәктәбе, китапханә, зур заллы дүрт катлы йорт та салып куйганнар. Анда татар театры эшләгән, газета-журналлар чыгарылган.

Бүгенге көндә дә татарлар үзләренең оешмаларын булдырганнар. Мәскәүдә 20 дән артык оешма бар. Вәкаләтле вәкиллек бу оешмалар белән бәйләнештә тора. Моның өчен вәкиллектә махсус бүлек тә бар. Күптән түгел вәкиллек каршында яшьләр оешмасы барлыкка килде. Аңа Мәскәүнең югары уку йортларында Татарстаннан килеп укучы студентлар да, Мәскәүдә яшәүче татар егетләре һәм кызлары да керә. Шулай ук вәкиллек каршында оештырылган «Фатиха» фонды талантлы яшьләргә булышуны төп максат итеп куя.

Гомумән әйткәндә, вәкаләтле вәкиллек татар оешмаларына зур ярдәм итә.

**Сораулар**

Татарстанның вәкаләтле вәкиллекләре кайсы илләрдә бар?

Бүгенге көндә Татарстанның Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиллеген кем җитәкли?

Мәскәүдә яшәүче татарлар үзара ничек аралашалар?

**Бирем.** Татарстанның төп законы – Конституция турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- Конституциядә билгеләнгән хокуклар;
- Конституциядә билгеләнгән бурычлар;
- Татарстанның халыкара эшчәнлеге.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ КОНСТИТУЦИЯСЕ

Конституция — төп закон ул. Анда республиканың иҗтимагый һәм икътисади төзелеш нигезләре, гражданнарның хокуклары һәм бурычлары билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Конституциясе 1992 нче елның 6 нчы ноябрендә кабул ителде. Конституциядә әйтелгәнчә, Татарстанда барлык хакимият халык кулында. Җир, су, урман һәм башка табигать байлыклары, дәүләт бюджеты

акчалары, дәүләт банклары активлары, мәдәни һәм тарихи хәзинәләр — бөтенесе халык байлыгы.

Татарстанның Конституциясе сәяси, икътисади, социаль һәм мәдәни тормышның барлык өлкәләрендә гражданнарның тигез хокукларын гарантияли. Республикабызда барлык гражданнар тигез хокуклы һәм тигез бурычлы. Дәүләт аларның тормышын, сәламәтлеген, шәхси иреген яклый. Республика гражданнары хезмәткә, ялга, медицина ярдәменә, чиста әйләнә-тирә мохиткә, торакка, дәүләт уку йортларында түләүсез белем алуга һәм башка хокукларга ия.

Дәүләт гаилә турында кайгырта, ана белән баланың сәламәтлеген саклауга һәм балаларны тәрбияләүгә аерым игътибар бирә. Татарстанда һәрбер кешегә сүз, матбугат, фикер һәм инану иреге бирелә.

Татарстанда дәүләт телләре — тигез хокуклы татар һәм рус телләре. Конституция нигезендә Татарстан Республикасы башка дәүләтләр белән ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштыра, ике яклы килешүләр төзи, вәкиллекләр белән алмаша, халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнаша.

Татарстан Республикасында яшәүче барлык кешеләр Конституцияне һәм законнарны үтәргә бурычлы. Алар башка гражданнарның намусын һәм милли горурлыгын хөрмәт итәргә, закон тәртибендә салымнар түләргә һәм хәрби хезмәт үтәргә тиеш. Шулай ук барлык гражданнар табигатькә сакчыл мөнәсәбәттә булырга, мәдәни хәзинәләрне һәм тарихи истәлекләрне сакларга, башка илләрнең халыклары белән хезмәттәшлекне үстерергә, бөтен дөньяда тынычлыкны ныгытырга бурычлы.

**Сораулар**

Татарстан Республикасының Конституциясен укыганыгыз бармы?
Сүз ирегең ничек аңлыйсыз?
Сезнең нинди хокукларыгыз бар?

**Бирем.** Татарстанның тарихы турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- Идел буе Болгар дәүләтенең үсеше;
- Болгар дәүләтенең дәвамчысы буларак Казан ханлыгы һәм Казан губернасы;
- Татарстанның бүгенге уңышлары.

## ТАТАРСТАН ТАРИХЫННАН

Мең еллар элек Идел белән Кама кушылган җирдә болгар кабиләләре яшәгән. X гасырда болгар кабиләләре дәүләт булып оешкан. Идел буе Болгар дәүләте Европаның көнчыгышында беренче зур дәүләт булган. 922 нче елда болгарлар ислам динен кабул иткәннәр. Бу вакыйга Болгар дәүләтенең үсешенә зур йогынты ясаган. Болгар иле ислам илләре белән тыгыз бәйләнешләр урнаштырган. Болгарлар башка дәүләтләр белән сәүдә иткәннәр, акча сукканнар, төрле кораллар, савыт-саба ясаганнар. Болгарларның үз язулары булган, фән, мәдәният, мәгариф үсеш алган.

1236 нчы елда монгол явы Болгар дәүләтен басып ала. Болгар дәүләте җимерелә һәм Алтын Урдага кертелә. Алтын Урда таркалганнан соң, XV гасырда яңа дәүләт — Казан ханлыгы төзелә. Биредә яшәүчеләрне Казан татарлары дип йөртә башлыйлар. Казан ханлыгы Бөек Болгарның дәвамы була. Казан ханлыгында игенчелек һәм тукучылык белән шөгыльләнгәннәр, матур биналар, мәчетләр, мәктәп-мәдрәсәләр төзегәннәр. Казан шәһәрендә гыйлем йортлары күп булган һәм аларда укырга-язарга, матур итеп китап күчерергә өйрәткәннәр. Илдә ханнан кала икенче кеше сәед булган. Сәедләр мәдрәсәләр тотканнар, мәгърифәт таратканнар.

XVIII гасырда Казан шәһәре Казан губернасы үзәгенә әверелгән. Казан губернасы хуҗалык үсеше ягыннан Россиядә алдынгы урында торган. Икътисади тормышның нигезен авыл хуҗалыгы тәшкил иткән. Казанда зур остаханәләр, завод-фабрикалар барлыкка килгән. Шәһәр тиз үсеш алган. Бу чорда Казан Россиянең иң эре сәүдә үзәкләреннән саналган. Анда телефон үткәрелгән, шәһәрнең үзәк урамнарында трамвай йөри башлаган, тимер юл челтәре киңәйгән.

1920 нче елда Татар автономияле республикасы төзелә. 1921 нче елда татар теле беренче тапкыр дәүләт теле дип игълан ителә. Сугыштан соңгы елларда Татарстанда югары сыйфатлы товарлар җитештерелә башлый. 1950 нче елда «Татнефть» берләшмәсе төзелә, һәм республикабызның икътисадында яңа тармак — нефть промышленносте барлыкка килә. 1956 нчы елда Татарстан нефть чыгару буенча СССРда беренче урынга чыга.

1990 нчы елда Татарстан Республикасының суверенлыгы турында Декларация кабул ителгәннән соң, Татарстанның Дәүләт Советы төзелде, беренче Президенты сайланды, дәүләт символлары булдырылды.

Бүгенге көндә Татарстан башка республикалар, чит илләр белән турыдан-туры килешүләр төзи, тыгыз һәм ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштыра, башка республикаларда, өлкәләрдә һәм чит илләрдә вәкиллекләрен ача.

Хәзерге вакытта Татарстан — Россиянең иң алдынгы төбәкләреннән берсе.

**Сораулар**

Хәзерге Татарстан җирендә нинди дәүләтләр булган?
XXI гасырда республика ничек үзгәрде?

Соңгы елларда Татарстан кайсы өлкәләрдәге казанышлары белән дөньяда танылу алды?

**Бирем.** Бөтендөнья татар корылтае турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- Бөтендөнья татар конгрессының оешуы;
- Башкарма комитетның эшчәнлеге;
- Татар конгрессының татарларны берләштерүдәге роле.

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОРЫЛТАЕ

Дөньяда җиде миллионнан артык татар исәпләнә. Аларның биш миллионга якыны Россия Федерациясендә яши. Татарстаннан тыш, татарлар Ульяновск, Чиләбе, Оренбург, Самара, Саратов, Пенза өлкәләрендә, БДБ илләрендә, Балтыйк буе дәүләтләрендә, ерак чит илләрдә дә яшиләр.

1992 нче елда, татарларны берләштерү максатыннан, Бөтендөнья татар конгрессы булдырылды. Шул ук елның җәендә Казанда Беренче Бөтендөнья татар корылтае үтте. Конгресска татарлар яши торган барлык төбәкләрдән дә диярлек меңнән артык кеше килде. Анда даими эшли торган орган — Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты төзелде. Башкарма комитет, иң беренче чиратта, Татарстан Республикасының башка дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен ныгытырга, татар милләтен тупларга, төрлек чаралар үткәрергә ярдәм итә.

Башкарма комитет, чит төбәкләрдә милли мәктәпләр ачу, татар газета-журналлары, җирле радио һәм телевидение проблемаларын хәл итү өчен, хакимият җитәкчеләренә мөрәҗәгать итә. Конгресс бинасында массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләре белән киңәшмәләр уза. Башкарма комитет шулай ук татарлар яши торган төбәкләрдә күчмә утырышлар да уздыра. Бу эшләр яхшы нәтиҗәләр бирә.

Бүгенге көндә төрле төбәкләрдә һәм илләрдә 130 дан артык татар милли оешмасы эшли. Бөтендөнья татар корылтаеның Башкарма комитеты Татарстанның чит илләрдәге вәкиллекләре һәм милли оешмалар белән тыгыз бәйләнештә тора. Конгрессның эшчәнлеге татарларның рухи үсешендә әһәмиятле роль уйный.

Бөтендөнья татар конгрессы 5 елга бер тапкыр үткәрелә.

**Сораулар**

Татар диаспоралары турында нәрсәләр беләсез?

Башка илләрдәге татарлар бер-берсе белән ничек аралашалар?
Чит илләрдәге татарлар Казанга киләләрме?

**Бирем.** Чит илләрдәге татар диаспоралары турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- татарларның яшәү урыннанры;
- иң зур татар диаспоралары;
- чит илләрдәге татарларның үзара аралашуы.

## ЧИТ ИЛЛӘРДӘГЕ ТАТАРЛАР

Татарларның күпчелеге Татарстанда яшәсә дә, төрле елларда, төрле сәбәпләр аркасында чит илләргә киткән татарлар да бар. Татарлар Чиләбе, Оренбург, Пермь, Ульяновск өлкәләрендә, Башкортстанда, Удмуртиядә, Себердә, Литвада, һәм башка төбәкләрдә яшиләр. Ерак чит илләрдә - Төркиядә, Финляндиядә, Польшада, Австралиядә, Кытайда, Германиядә, Америкада да татар диаспоралары бик көчле.

Элек чит илләрдәге татарларның Татарстанга килү мөмкинлекләре элемтәләре булмаган, әмма алар туган телләрен онытмаганнар, саклап калганнар, татар халкы турындагы истәлекләрне буыннан буынга тапшырып килгәннәр.

XX гасырның 90 нчы елларыннан соң аларга әти-әниләренең туган җирләре белән якыннан танышырга мөмкинлекләр булдырылды. 1992 нче елда татарларны берләштерү максатыннан, Казанда Беренче Бөтендөнья татар конгрессы үткәрелде. Чит илләрдә яшәүче татарлар Татарстандагы туганнары, дуслары белән очраштылар. Шул көннән бирле алар Татарстан белән кызыксынып яшиләр.

Хәзерге вакытта иң зур татар диаспоралының берсе Төркиядә. Анда 25 меңгә якын татар  яши. Бу илгә татарлар XIX гасыр ахырында һәм XX гасырның 20—40 нчы елларында күчеп киткәннәр. Польшада 5 меңгә якын татар яши. Мондагы татар диаспорасы берничә дулкын эмигрантлардан формалашкан. Татарлар, нигездә, дәүләтнең көнчыгышында яшиләр. Фин татарларына килгәндә, аларның күбесе Хельсинки, Тампере һәм башка шәһәрләрдә яши. Татарлар бу илгә XIX гасыр ахырында — XX гасыр башында сәүдәгәр буларак килгәннәр.

Америка Кушма Штатларындагы татар диаспорасының нигезен Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Европа һәм Азия илләреннән күчеп килгән татарлар тәшкил итә. Татар диаспоралары шулай ук Канадада да, Австралиядә дә, Германиядә дә бар. Чит илләрдәге татар гаиләләре бер-берсе белән аралашалар, милли бәйрәмнәрне билгеләп үтәләр, төрки халыкларның сәнгате һәм мәдәнияте белән кызыксынып яшиләр.

Татарстан хөкүмәте, Бөтендөнья татар корылтае чит ил татарлары белән тыгыз элемтәдә тора.

**Сораулар**

Татарлар кайсы чорларда чит төбәкләргә күчеп киткәннәр?
Чит илләрдәге татарлар кайда очраша алалар?
Чит ил татарлары Татарстан турында каян мәгълүмат алалар?

**Бирем.** Татарстанның төп китапханәсе турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:
- китапханәнең тарихи бинада урнашуы;
- беренче җәмәгать китапханәсе ачылуы;
- китапханәдәге бүлекләр.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ

Татарстанның Милли китапханәсе Казанда, Кремль урамында иң матур биналарның берсендә урнашкан. Бу бина фабрикант А.Ушков үтенече буенча күренекле архитектор Карл Мюфке тарафыннан салдырыла һәм бизәлә. Бүгенге көндә дә китапханәнең залларында бу йортның хуҗасы Алексей Ушковтан калган бәллүр люстралар эленеп тора. Шул чорның шәмдәлләре, сәгатьләре, каминнары, серле мәгарәләре — барысы да үз урынында.

Казанда беренче җәмәгать китапханәсе ачылуга зур өлеш керткән кешеләр булып этиле-уллы Второвлар санала. Иван Алексеевич Второв гомере буе төрле телләрдәге китаплар, журналлар җыйган. Аның байлыгы мирас булып улы Николай Иванович Второвка күчкән. Петербургка күчеп киткәндә, Николай Второв этисенең китапханәсен шәһәр идарәсенә бүләк итеп калдырган. Шулай итеп, Казанда беренче китапханә ачылган.

Татарстанның төп китапханәсе 1991 нче елда Милли китапханә статусын алды. Бүгенге көндә ул дөньяда татар китабын, республика тормышына караган әдәбиятны туплау, саклау һәм тарату белән шөгыльләнә. Аның хәзинәсендә 3 миллионнан артык китап һәм документлар саклана. 14 меңнән артык кульязма һәм сирәк очрый торган басма китаплар — китапханәнең байлыгы.

Китапханәдә төрле бүлекләр бар: борынгы кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге; дөнья әдәбияты бүлеге; сәнгать бүлеге; фәнни әдәбият, техник әдәбият, фәнни-методик әдәбият бүлекләре; туган якны өйрәнүгә багышланган басмалар бүлеге; матбугат бүлеге; чит ил әдәбияты бүлеге һәм башкалар.

Хәзерге вакытта Милли китапханә — Идел буе мәдәниятенең әһәмиятле үзәге. Ул халыкара танылу да алды: китапханәләрнең халыкара ассоциациясенә керде, аның барлык конгрессларында катнаша.

Китапханәнең эшчәнлеге күпкырлы. Анда фәнни-гамәли конференцияләр, язучылар белән очрашулар уздырыла, камера оркестры һәм җырчылар чыгыш ясый. Ел саен иң популяр китап конкурсына йомгак ясала. Шулай ук күргәзмәләр оештырыла, китапка багышланган әдәби кичәләр үткәрелә. Татарстанның Милли китапханәсе үзенең эшчәнлеге белән халыкларны якынайтуга зур өлеш кертә.

**Сораулар**

Сезнең Милли китапханәдә булганыгыз бармы?
Сезнеңчә, китапханәгә кемнәр күбрәк йөри?
Сез нинди китаплар укырга яратасыз?

**Бирем.** Татар матбугаты турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- беренче татар газетасы;
- төрле елларда нәшер ителгән татар газета-журналлары;
- бүгенге татар вакытлы матбугаты.

## ТАТАР МАТБУГАТЫ ТАРИХЫННАН

Татар вакытлы матбугаты тарихы XIX гасыр ахырыннан башлана һәм беренче төрки газета «Тәрҗеман»га барып тоташа (1883—1905). Газетаны күренекле җәмәгать эшлеклесе Исмәгыйль бәй Гаспралы чыгара. Бу газета, Бакчасарайда нәшер ителсә дә, бөтен төрки дөньядагы яңалыкларны яктыртып бара.

Татар телендә беренче газета исә 1905 нче елның сентябрендә дөнья күрә. Ул Петербургта чыга һәм «Нур» дип атала. Аның мөхәррире Гатаулла Баязитов була. Шул көннән алып төрле шәһәрләрдә яңа газета һәм журналлар чыга башлый. Октябрь аенда Казанда «Казан мөхбире» («Казан хәбәрчесе») газетасы дөнья күрә. Берничә айдан Уральск шәһәрендә «Фикер» газетасы басыла башлый. Аны күренекле татар шагыйре Габдулла Тукай һәм аның фикердәшләре чыгара. Шул ук елда Казан шәкертләре дә үз газеталарын булдыралар. Ул «Әльислах» дип атала һәм мәдрәсә шәкертләре тормышындагы төрле вакыйгаларны чагылдыра.

1905—1906 нчы елларда татар зыялылары тырышлыгы белән бик күп газета һәм журналлар чыга. Казанда «Азат» газетасын Галиәсгар Камал нәшер итә, ә «Таң йолдызы»на Гаяз Исхакый, Фуат Туктаров, Сәгыйть Рәмиевләр җитәкчелек итәләр. Оренбургта Хөсәен Ямашев тырышлыгы белән «Урал»

газетасы чыга. Анда эшчеләр тормышын яктырткан мәкаләләр басыла. Бу вакытта Оренбургта — «Карчыга», «Чүкеч», Әстерханда — «Туп», Казанда «Яшен» кебек сатирик журналлар да чыга. Алар татар матбугатының алга таба үсешенә зур йогынты ясыйлар һәм татар халкын милли рухта тәрбияләүдә мөһим роль уйныйлар.

Хәзерге вакытта татар телендә чыга торган газета һәм журналлар шактый күп. Татар халкы «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» газеталарын, «Казан», «Татарстан» журналларын яратып укый. «Сөембикә» журналы татар хатын-кызлары өчен нәшер ителә. Мәктәп, мәгариф өлкәсенә караган хәбәрләр «Мәгариф» журналында басыла.

Балалар өчен дә махсус басмалар бар. Бу — «Сабантуй» газетасы, «Ялкын», «Салават күпере» журналлары. Ә яшьләр тормышы турында «Татарстан яшьләре» газетасыннан, «Идел» журналыннан укып белергә мөмкин.

**Сораулар**

Сез нинди газета-журналлар укыйсыз?
Сез нәрсәләр турында мәкаләләр укырга яратасыз?
Журналист буласыгыз киләме?

**Бирем.** Татарстанның Милли музее турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- музейның төп максаты;
- музейның борынгы экспонатлары;
- табигатькә бәйле экспонатлар.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МИЛЛИ МУЗЕЕ

Татарстан җире зур тарихка ия. Аның бай тарихы музейларда чагыла. Республикабызның иң зур музее — Татарстанның Милли музее. Ул 1895 нче елның 5 нче апрелендә ачылган. Андагы экспонатларның төп өлешен туган якны өйрәнүче, күренекле археолог һәм тарихчы Андрей Федорович Лихачевның шәхси тупланмасы тәшкил итә. Шулай ук 1890 нчы елда үткәрелгән фәнни-сәнәгый күргәзмә материаллары да урын алган. Музейның беренче уставында болай дип язылган: «Музейның төп максаты — бу якның табигате, биредә яшәүче халыклар турында киң мәгълүмат бирү».

Музей архитектура һәм тарих истәлеге булган бинада урнашкан. Элек анда Сәүдә йорты булган. Бина XIX гасыр дәвамында төзелгән. Аның беренче архитекторы Ф. Е. Емельянов булган. Соңрак бу бина архитекторлар И. Бессонов, И. Колмаков, С. Козловалар тарафыннан үзгәртеп эшләнгән.

Милли музейның фондларында дөньяның төрле илләреннән җыелган 700 меңнән артык экспонат саклана. Алар арасында Болгар чорына караган әйберләр дә, Казан ханлыгы чорын да, Татарстанның бүгенгесен күрсәткән мәгълүматлар да бар. Болгар һөнәрчесенең җир йортлары, металлга төшерелгән бизәкләр, үзенчәлекле киемнәр, чигүле читекләр, бизәнү әйберләре, тәңкәле акчалар — болар барысы да музейга килүчеләрне ерак-ерак заманнарга алып китә.

Татарстан табигатенә — елга-суларына, урман-тауларына, кошларына һәм җәнлекләренә багышланган экспонатлар да бик кызыклы.

1981 нче елдан музей Татарстан Республикасының музейлар җәмгыятен җитәкли. Аңа республикабызда урнашкан 80 музей карый.

**Сораулар**

Сез кайсы музейларда булдыгыз?
Сезнеңчә, музейлар ни өчен кирәк?
Дөньяда иң зур музейлар ниндиләр?

**Бирем.** Сынлы сәнгать музее турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- музей заллары;
- татар өйләрен сурәтләгән әйберләр;
- музей хезмәткәрләренең эшчәнлеге.

## СЫНЛЫ СӘНГАТЬ МУЗЕЕ

Казанда Карл Маркс урамында бик матур ак йорт бар. Монда Сынлы сәнгать музее урнашкан.

Музей залларыннан үткәндә, үзеңне гасырлар буйлап сәяхәт иткән кебек тоясың. Беренче зал безне XVI гасырга алып килә: монда борынгы иконалар, чиркәү кирәк-яраклары урын алган. Икенче зал стеналарына алтынланган рамлы портретлар эленгән. Менә тагын бер зал. Монысына ап-ак каминнар, фарфор савыт-саба, көлкеле сыннар куелган. Аннан соң кергән залда наратлар үсә, урманнар шаулый, аланнарда кояш нурлары уйный. Бу — якташыбыз Иван Иванович Шишкин картиналары.

Икенче катта саклана торган әйберләр татар өйләрендә XX гасыр башында киң кулланылган: төрле төстәге җепләр белән чигелгән сөлгеләр, энҗе һәм сәйлән белән бизәлгән калфаклар, көмеш беләзекләр...

Бүгенге көндә музейда бик зур эш алып барыла. Фәнни хезмәткәрләр сәнгать әсәрләрен өйрәнәләр, яңаларын эзләп табалар. Рәссам-реставраторлар зарарланган картиналарны «дәвалый». Экскурсоводлар музейга килүчеләргә аның хәзинәләре турында сөйлиләр.

Беренче коллекция хуҗасы — Андрей Федорович Лихачев — үзе үк җыючы да, саклаучы да, галим дә булган. Аны аеруча археология фәне кызыксындырган. Үз чорында ул борынгы Болгар тарихын иң яхшы белүчеләрдән саналган. Хәзер А.Лихачев коллекциясенең археологик өлеше Татарстанның Милли музеенда саклана. А.Ф.Лихачев шулай ук сынлы сәнгать белән дә мавыккан, үзе дә рәсемнәр ясаган. Башка рәссамнарның картиналарын да җыйган. Замандаш рәссамнары И.Шишкин, А.Каменев картиналарын үзләреннән сатып алган. Узган гасыр рәссамнары Д.Левицкий, В.Боровиковский, В.Тропинин, А.Венецианов хезмәтләрен антикварлардан эзләп тапкан. Италия, Франция, Германия буйлап сәяхәт иткәндә, Көнбатыш Европа осталарының әсәрләрен алып кайткан. Сынлы сәнгать музее шушы картиналар галереясыннан башланган.

**Сораулар**

Казанда нинди кызыклы музейлар бар?
Сезнең Сынлы сәнгать музеенда булганыгыз бармы?
Хәзерге көн танылган рәссамнарыннан кемнәрне беләсез?

**Бирем.** Татар театры турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- татар театрына нигез салучы;
- беренче спектакльләр;
- татар театрының артистлары.

## ТАТАР ТЕАТРЫ

Татар профессиональ милли театрының туган көне — 1906 нчы елның 22 нче декабре. Бу көнне атаклы драматург, артист, режиссер Галиәсгар Камалның «Кызганыч бала» әсәре сәхнәләштерелгән. Г.Камал — татар драматургиясенә һәм театрына нигез салучы.

Беренче татар драма артистлары труппасы «Сәйяр» (сәяхәтче) дип атала. Ул Казанда Ильяс Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендә төзелә. Аннары труппага сәләтле артист, режиссер Габдулла Кариев килә һәм тиздән труппа белән җитәкчелек итә башлый.

Беренче елларда спектакльләр Казанда оештырылган «Шәрык клубы»нда куела. Г.Камалның «Беренче театр», «Безнең шәһәрнең серләре» һәм башка бик күп әсәрләре, шулай ук Фатих Әмирханның, Гаяз Исхакыйның драмалары зур уңыш казана.

Башта татар театры Казандагы элек Купецлар йорты булган бинага урнаша, ә 1926 нчы елда Горький урамына, элек Чиновниклар клубы урнашкан һәм зур тамаша залы булган бинага күчә. 1986 нчы елда исә Татар дәүләт академия театры өчен Татарстан урамында махсус бина салына.

20—30 нчы еллар — татар театрында музыкаль драма жанры туган чор. Шул вакыттан театр музыкаль драма театры сыйфатында яши. Бу елларда К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе» әсәрләре сәхнәдән төшми. Татар халкының күренекле композиторы С.Сәйдәшев бу әсәрләргә музыка яза.

Шәхес культы елларында татар театрының иң яхшы вәкилләре юк ителә: театрның баш режиссеры, үлемсез «Зәңгәр шәл» авторы — К. Тинчурин 1938 нче елда атыла; беренче профессиональ композитор С.Сәйдәшев театрдан куыла...

Бөек Ватан сугышы башлангач, Татар дәүләт академия театрының күп кенә артистлары фронтка китә һәм сугыш кырларында ятып кала. Нәтиҗәдә 30—40 нчы елларда да театр зур югалтулар кичерә. Театр тормышында җанлылык бары тик 50 нче елларда гына күзәтелә башлый. Театрга яшь драматурглар, режиссерлар килә. Мәскәүдәге Щепкин училищесын тәмамлап, бер төркем яшьләр кайта. Казан театр училищесын тәмамлаучылардан иң яхшылары труппага алына.

1966 нчы елдан башлап, 40 елга якын театрның баш режиссеры булып Марсель Сәлимҗанов эшли (2002 нче елда вафат). Ул заманча репертуар булдыра, һәм театрда мелодрамалар, водевильләр, халык драмалары куела башлый. Шуңа күрә дә тамаша залы беркайчан да буш булмый.

Татар театрында татар, рус, дөнья классикасы тәрҗемә әсәрләре бар. Хәзерге вакытта татарлар да, руслар да, чит ил кунаклары да театрга яратып йөриләр.

**Сораулар**

Татар театрларына йөрисезме?
Хәзерге вакытта театрлар репиртуарында нинди спектакльләр бар?
Сезгә кайсы актер/артист күбрәк ошый һәм ни өчен?

**Бирем.** Татар опера һәм балет театры турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- татар опера театрының оешуы;
- театрда татар репертуары;

- театрда үткәрелә торган фестивальләр.

## ТАТАР ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ ТЕАТРЫ

«Алтынчәч» операсы, «Шүрәле» балеты, «Башмагым» музыкаль комедиясе — татар музыка сәнгатенең классик әсәрләре.

1938 нче елда татар халкының үз опера һәм балет театрын булдыру татар сәнгатен дөньяда таныту дигән сүз иде... Опера һәм балет театрында татар репертуары елдан-ел өстәлә барган. Классик исемен алган Н. Җиһанов, Ф. Яруллин, Җ. Фәйзи артыннан М. Мозаффаров, Ә. Бакиров, Р. Кәлимуллин, Л. Хәйретдинова кебек композиторлар театр тарихына зур өлеш кертәләр.

Бүген Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының абруе югары. Ул академия театры исемен лаеклы йөртә. Театр коллективы һәм җитәкчеләре музыка сәнгатенең киләчәген кайгыртып яшиләр.

...Театрда 1981 нче елдан бирле Ф. Шаляпин исемендәге халыкара опера фестивале үткәрелә. 1987 нче елдан Р. Нуриев исемендәге халыкара балет фестивале оештырыла. Дөньякүләм танылган артистлар фестиваль спектакльләрендә катнашуны зур казаныш дип саныйлар.

Театр коллективы гастрольләргә еш йөри. «Борис Годунов», «Богема», «Риголетто», «Травиата», «Дон Кихот», «Баядерка» спектакльләрен Голландия, Бельгия, Германия, Испания, Франция, Португалия сәхнәләрендә күрсәтеп, театр Көнбатыш Европада дан казанды.

**Сораулар**

Сезнең татар опера һәм балет театрында булганыгыз бармы?
Бу театр кем исемен йөртә?
Рудольф Нуриев турында нәрсәләр беләсез?

**Бирем.** Сабан туе турында сөйләгеә. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- бәйрәмнең үткәрелү вакыты һәм урыны;
- көрәш һәм ат чабышы;
- милли уеннар.

## САБАН ТУЕ

Сабан туе — элек-электән татар халкының яраткан бәйрәме. Сабан туе — язгы эшләрне төгәлләү бәйрәме. Ул, гадәттә, июнь башында үткәрелә, шимбә

көнне — авылларда, ә якшәмбе көнне район үзәкләрендә була. 25 нче июньнән соң Казанда үтә.

Сабан туе Идел буенда яшәгән барлык милләтләрнең дә уртак бәйрәменә әйләнде. Анда татар халкы белән бергә рус, мари, удмурт, башкорт һәм башка халыклар да катнаша. Бәйрәмне үткәрү өчен, тигез һәм уңайлы урын сайлана. Бу урын мәйдан дип атала. Авыл халкы һәм кунаклар, мәйданга бәйрәмчә киенеп, кайсы җәяү, кайсы машина белән килә.

Сабан туенда иң зур ярыш — көрәш. Татар көрәшендә сөлге тотып көрәшәләр. Һәр көрәшче көндәшенең биленнән сөлге белән урап тота һәм аны җиргә егарга тырыша. Көрәшне малайлар башлап җибәрәләр. Аннары мәйданда, чиратлашып, яшүсмерләр, егетләр, урта яшьләрдәге ирләр көрәшә. Көндәшен аркасына яткырган кеше җиңә. Көрәштә батыр калучыга тәкә һәм кыйммәтле бүләк бирәләр.

Сабан туенда икенче зур ярыш — ат чабышы. Атлар 5—8 километр ераклыктан мәйданга чабып керәләр. Бу ярышта беренче килгән атның хуҗасына да зур бүләк бирәләр, ә атның муенына яулыклар, сөлгеләр бәйлиләр.

Мәйданда төрле халык уеннары һәм спорт ярышлары оештырыла: шома колгага менеп, әтәч алу; капчык киеп йөгерү; капчык белән сугышу; чүлмәк вату; аяк бәйләп йөгерү; аркан тартышу һәм башка кызыклы уеннар. Йөгерү, биеклеккә һәм озынлыкка сикерү, волейбол, теннис буенча спорт ярышлары да үткәрелә. Мәйданда артистлар да чыгыш ясый: бииләр, җырлыйлар. Балалар да күңел ачалар, төрле уеннарда катнашалар.

Ярышлар һәм уеннар беткәч, кешеләр өйләренә таралалар. Һәр йортта табын әзерләнә, бәйрәм ашлары пешерелә. Кичен яшьләр өчен җыр-биюләр дәвам итә. Сабан туе — күңелле һәм шатлыклы бәйрәм.

**Сораулар**

Сезнең Сабан туенда катнашканыгыз бармы?
Сабан туе тагын кайларда үткәрелә?
Сезнең нинди милли бәйрәмнәрне беләсез?

**Бирем.** Татар халкының күренекле мәгърифәтчесе Ш.Мәрҗани турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- булачак мәгърифәтченең белем алуы;
- мәдрәсәдә укыту;
- фәнни хезмәтләр язу.

## ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ
## (1818—1889)

Ш.Мәрҗани — Россия халыкларының бөек мәгърифәтчесе.

Ул 1818 нче елда Арча ягында туган. Авыл мәдрәсәсендә белем алгач, Бохарага киткән һәм Урта Азиядә 10 ел чамасы яшәгән. Ул дәвердә Казан белән Бохара арасында сәүдә бәйләнешләре нык булган. Мәрҗанинең тырышлыгы һәм гыйлеме турындагы хәбәрләр үзе Бохарада чакта ук Казанга килеп җиткән.

Казанга кайткач, ул мәдрәсә ачып укыта башлый. Аның дәресләре тирән эчтәлекле, төрле тарихи мәгълүматларга бай була. Ул шәкертләрен дөньяви фәннәр белән таныштыра. Галим, җәмәгатьчелек көче белән, Европа тибында мәктәп төзетә. Анда, парталар куеп, расписание буенча дәресләр бирә. Бу мәктәптә Мәрҗани тарих, география, геометрия, астрономия, әдәбият фәннәрен укытырга керешә.

Ш.Мәрҗани, 50 елдан артык мәдрәсәдә шәкертләр укытып, 200 дән артык яхшы белемле укытучы әзерли. Ш.Мәрҗани тырышлыгы белән кертелә башлаган фәннәр укыту башка мәдрәсәләргә дә күчә. Алга таба яңа ысул белән укыту ысулы Идел буе, Урал, Себер, Урта Азия мәдрәсәләрендә дә гамәлгә кертелә. Хәтта Ташкент шәһәрендә дә «Мәрҗани мәктәбе» ачыла һәм 1930 нчы елга кадәр эшли.

Атаклы галим Шиһабетдин Мәрҗани тарих, философия, астрономия һәм башка фәннәр буенча 30 дан артык зур хезмәт язган. Ул тарихка аеруча зур әһәмият биргән. Урта гасыр галимнәренең әсәрләрен өйрәнгән. Ерак авылларга чыгып, борынгы кабер ташларын тикшергән, халык телендә сакланган истәлекләрне туплаган, төрле дәүләт эшлеклеләренең хатларын чагыштырып өйрәнгән, борынгы кульязмалар һәм фәнни китаплар җыйган.

Шиһабетдин Мәрҗани чын мәгънәсендә мәгърифәт реформаторы булып санала.

**Сораулар**

Шиһабетдин Мәрҗани кебек танылган башка мәгърифәтчеләрдән кемнәрне беләсез?

Мәгърифәтчеләр гомерләрен нәрсәгә багышлыйлар?

Бүгенге көндә Татарстанда Мәрҗани исеме белән бәйле нинди урыннар бар?

**Бирем.** Күренекле татар галиме Каюм Насыйри турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- татар теле укытучысы булып эшләү;
- татарларга рус телен укыту;

- дәреслекләр һәм фәнни хезмәтләр язу.

## КАЮМ НАСЫЙРИ
## (1825—1902)

XIX йөзнең 60 нчы елларыннан башлап, ярты гасыр дәвамында тырыш һәм нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән педагог, язучы, галим Каюм Насыйри — татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкиле.

Каюм Насыйри 1825 нче елда туган. Каюмның бабалары һәм әтисе укымышлы кешеләр булалар. 1841 нче елда аны Казанга мәдрәсәгә укырга җибәрәләр. Анда ул гарәп, фарсы телләрен өйрәнә, татар әдәби теле буенча белемен арттыра.

1855 нче елда Каюм Насыйрины Духовное училищега татар теле укытучысы итеп чакыралар. Соңрак бу училищеның дәвамы булган Духовная семинариядә ул 1870 нче елга кадәр татар теле укыта. К. Насыйри укытучылык эшенә бик җитди карый. Аның семинариядәге шәкертләре арасыннан да татар теле галимнәре чыга.

1871 нче елдан башлап, К. Насыйри татар балаларына рус теле укытуга керешә. Ләкин аңа бу эшне башкару җиңел булмый. Бина табу, балаларны укуга тарту өчен, күп тырышлык күрсәтергә, төрле авырлыклар кичерергә туры килә.

1879 нчы елдан К. Насыйри гомерен язучылык эшенә һәм фәнгә багышлый. Аның фәнни һәм әдәби хезмәтләре шул вакытларда дөнья күрә. Галим барлык көчен китап һәм дәреслекләр язуга, алган акчасын аларны бастыруга сарыф итә.

Каюм Насыйри — XIX йөз татар мәгърифәтчеләре арасында иң эшлеклесе. Галим ана телендә математика, география, ботаника, табигать белеме фәннәре буенча дәреслекләр яза, еллык өстәл календарьлары чыгара.

Каюм Насыйриның иң зур эшчәнлеге тел өлкәсенә карый. Ул татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеген төзи, русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр төзеп бастыра. Татар теленең фәнни грамматикасын төзүгә дә нигезне К. Насыйри сала. Аның хезмәтләре үз вакытында ук тел галимнәренең югары бәясен ала.

Шул ук вакытта К. Насыйри, рус телен үзләштерү өчен, уку китаплары төзи һәм, рус теленең грамматикасын язып, аларны бастырып тарата. Ул рус, татар грамматикаларында булган аермаларны өйрәнә һәм аларны укучыларына аңлата. К. Насыйри керткән бу яңалык хәзерге көндә дә, балаларга икенче телне өйрәткәндә, уңышлы методларның берсе булып санала.

**Сораулар**

Каюм Насыйри гомерен нәрсәгә багышлаган?
Каюм Насыйри тел укыту методикасына нинди яңалыклар керткән?

Казандагы Каюм Насыйри музеенда булганыгыз бармы?

**Бирем.** Танылган галим һәм педагог Мөхетдин Корбангалиев турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- программа һәм дәреслекләр төзү;
- укытучылык эшен алып бару;
- русларга татар телен укытудагы роле.

## МӨХЕТДИН КОРБАНГАЛИЕВ
(1873—1941)

XX йөз башында яшәгән татар мәгърифәтчеләре һәм галимнәре арасында профессор Мөхетдин Корбангалиев күренекле урын алып тора.

Ул 1873 нче елда крестьян гаиләсендә туа. Авылда белем алгач, Казанда Татар укытучылар мәктәбендә укый. Шул елларда ул танылган татар педагогы, мәгърифәтче Каюм Насыйри белән таныша. Укытучылар мәктәбен тәмамлагач, М.Корбангалиев төрле урыннарда рус телен һәм арифметика укыта, башлангыч мәктәпләр өчен күп санлы дәреслекләр яза.

Казанда «Мәктәп» журналы чыга башлагач, анда М.Корбангалиевнең укыту методлары һәм төрле фән программалары турында язган мәкаләләре басыла. Ул татар-башкорт мәктәпләре өчен дәреслекләр, программалар төзи, татар мәктәпләре ачуда башлап йөри, авыл мөгаллимнәренең педагогик киңәшмәләрендә катнаша.

Татар автономияле республикасы төзелгәч, тынгысыз мөгаллим мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеген дәвам итә. Ул шәһәр мәктәпләрендә инспектор, халык мәгариф бүлегендә мөдир урынбасары була. Аның җитәкчелегендә Татарстанда Педагогия җәмгыяте төзелә. Озак еллар М.Корбангалиев аның рәисе булып эшли. Шул ук вакытта укытучылык эшен дә алып бара. Казан университетында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире була.

М.Корбангалиев — русларга татар теле укытуның фәнни-методик нигезләрен эшләүгә зур өлеш керткән галим. Ул — 100 дән артык дәреслек, кулланмалар авторы һәм мөхәррире.

**Сораулар**

Башка милләт вәкилләренә татар теле укыту юнәлешендә галим нинди эшләр башкарган?

Хәзерге вакытта башка милләт вәкилләренә татар телен өйрәнү өчен нәрсәләр бар?

Сезнеңчә, татар телен өйрәнү кызыкмы һәм ни өчен?

**Бирем.** Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:
- шагыйрьнең туган ягы;
- Уральск шәһәрендә яшәү һәм иҗат итү;
- Казан чоры.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ
## (1886—1913)

Әгәр дә дөньяда бик аз яшәп тә, күп эшләр эшләп киткән язучылар турында сүз бара икән, аның берсе, һичшиксез, Габдулла Тукай булыр. Аңа бит үлгәндә нибары егерме җиде яшь кенә була. 1886 нчы елның апреле һәм 1913 нче елның апреле. Яз аенда туган, яз аенда үлгән...

Шагыйрьнең туган ягы — матур табигатьле Казан арты. Ул 1886 нчы елның 26 нчы апрелендә хәзерге Арча районының Кушлавыч авылында туа. Әтисе мулла була. Габдуллага дүрт ай ярым булуга, ул үлә. Әнисе, аны Шәрифә исемле карчыкка вакытлыча калдырып, Сасна авылы (хәзерге Балтач районында) мулласына кияүгә чыга. Менә шуннан шагыйрьнең авыр тормышы башлана. Габдулла авыр язмыш кичерә: ятимлекләр, фәкыйрьлекләр, кимсетүләр...

1895 нче елны Габдулланы әтисе ягыннан апасы Уральск шәһәренә алдыра. Анда ул мәдрәсәдә һәм бер үк вакытта өчьеллык рус мәктәбендә укый. Мәдрәсәдә гарәп, төрек, фарсы телләрен бик яхшы үзләштерә, рус телен дә өйрәнә. Бу аңа Европа әдәбияты белән танышырга мөмкинлек бирә.

Уральск — шагыйрьнең журналист һәм шагыйрь буларак танылган урыны. Монда аның шигырьләре басыла башлый. Бу чорда Габдулла Тукай төрле әдәби журналларда эшли. 1905—1907 нче елларда аны Казанда, Оренбургта, Петербургта яхшы белә башлыйлар.

Габдулла Тукай 1907 нче елның көзенә чаклы Уральскида яши, аннан Казанга килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр Казанда була. Сигез ел буена иҗат итү чорында ул ун мең юлдан артык шигырь, иллегә якын басма табак проза әсәре язарга өлгерә.

Татар халкының Г.Тукайга хөрмәте бик зур. Казанның үзәгендә шагыйрьгә һәйкәл куелган, туган авылы Кушлавычта, Кырлайда аның истәлекләре музейда кадерләп саклана. Татарстанның төрле шәһәрләрдендәге иң матур урамнар аның исемен йөртәләр. Шигырьләре — җырга, әкиятләре балетка әйләнде. Г.Тукай турында поэмалар, драмалар, романнар, симфонияләр язылды.

**Сораулар**

Тукайны нәрсә Тукай иткән?

Тукайның нинди шигырьләрен беләсез?

Хәзерге вакытта Тукай исеме белән бәйле нинди урыннарны атый аласыз?

**Бирем.** Күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- укытучы һөнәрен сайлау;
- беренче әсәрләре;
- эмиграциядә яшәү һәм иҗат итү.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ
(1878—1954)

Гаяз Исхакый — татар халкының күренекле язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе.

Ул 1878 нче елның 22 нче февралендә хәзерге Татарстан Республикасының Чистай районында туган. Чистай, Казан мәдрәсәләрендә белем алган. Соңыннан укуын Татар укытучылар мәктәбендә дәвам иткән. Аны тәмамлагач, Оренбургта укытучы булып эшләгән.

1904 нче елда ул Казанга әйләнеп кайта. Төрле мәкаләләр язып бастыра, җәмәгать эшендә актив катнаша. «Бай углы», «Кәләпүшче кыз», «Өч хатын белән тормыш», «Ике гашыйк», «Ике йөз елдан соң инкыйраз» — Гаяз Исхакыйның беренче әсәрләре.

XX гасыр башында язылган әсәрләре — «Зиндан», «Тормышмы бу?», «Солдат», «Алдым-бирдем», «Зөләйха», «Тартышу», «Мөгаллим».

1919 нчы елдан алып Гаяз Исхакыйга төрле илләрдә — Төркиядә, Германиядә, Польшада яшәргә туры килә. Биредә ул газета чыгару эшен активлаштыра, татар милләте проблемаларын кайгырта, яңа романнар, повестьлар, драмалар яза. Эмиграциядә иҗат иткән әсәрләре арасында «Көз», «Дулкын эчендә», «Җан Баевич», «Олуг Мөхәммәд» зур игътибарга лаек.

Гаяз Исхакыйның әсәрләре озак еллар махсус фондларда сакланды, эшчәнлеге бозып аңлатылды. Хәзер Г.Исхакый тулысынча акланды, аның бай әдәби мирасы халыкка кире кайтты.

1991 нче елда Татарстан Язучылар берлеге Гаяз Исхакый исемендәге премия булдырды.

**Сораулар**

Күренекле татар язучылары арасында Гаяз Исхакый иҗаты ни өчен аерым урын алып тора?

Язучыга кайларда яшәргә туры килгән?

Гаяз Исхакыйның бай әдәби мирасы белән кайда танышырга мөмкин?

**Бирем.** Күренекле язучы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- язучының балачагы;
- беренче әсәрләре;
- көрәшчеләр сафына басу.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ
## (1887—1938)

Башкортстан җирендә, биек таулар, яшел болын һәм урманнар кочагында Солтанморат дип аталган бер татар авылы урнашкан. Менә шушы авылда 1887 нче елда татар халкының атаклы язучысы Галимҗан Ибраһимов туган.

Кечкенә Галимҗан табигать кочагында үсә, яшьли үк кыр эшләрендә булыша, олырак малайлар белән, төн кунып, ат сакларга йөри. Галимҗанны тирә-як табигате кызыксындыра: биек-биек таулар, серле кара урманнар, борылып-борылып аккан елгалар, чәчәкләргә күмелеп яткан болыннар аңа әкияттәге төсле сихерле күренәләр. Язучы булып киткәч, Галимҗан Ибраһимов кечкенә вакытта алган шушы матур тәэсирләрен үзенең әсәрләрендә бөтен гүзәллеге белән чагылдыра башлый. Мәсәлән, аның «Алмачуар» хикәясе шуңа дәлил була ала. Шундый ук матур хисләр Галимҗан Ибраһимовның «Яз башы», «Табигать балалары», «Көтүчеләр», «Казакъ кызы» кебек әсәрләрендә дә чагылыш таба.

Галимҗанның беренче укытучысы әнисе була. Аннан соң ул күрше авылда мәдрәсәдә укый, шул ук вакытта үз авылларындагы башлангыч рус мәктәбен дә тәмамлый. Соңыннан Галимҗан Ибраһимов Оренбург һәм Уфа мәдрәсәләрендә дә укуын дәвам итә. Мәдрәсә белеме белән генә чикләнмичә, ул күп китаплар, газета материалларын бик кызыксынып укып бара, рус язучыларының әсәрләре белән таныша. Аның күңелендә яңа фикерләр туа. Менә шуңа күрә дә ул 1905 нче елгы беренче рус революциясен зур өметләр белән каршы ала, алдынгы көрәшчеләр сафына баса.

1909 нчы елда Галимҗан, университетта уку теләге белән, Казанга килә. Ләкин аны укырга алмыйлар. Ул үзлегеннән күп укый башлый. Революцион вакыйгалар белән кызыксына. Тиздән аның азатлык өчен көрәшүчеләргә багышланган, халыкның авыр тормышын, иске гадәтләрне тәнкыйтьләгән зур күләмле «Яңа кешеләр», «Кызыл чәчәкләр», «Безнең көннәр», «Татар хатыны ниләр күрми» кебек әсәрләре языла.

Тормышның зур кыенлыкларын күргән Галимҗан Ибраһимов авырый башлый һәм, дәвалану өчен, Кырымга китә. Авыру булуына карамастан, ул иҗат эшен ташламый, яңадан-яңа әсәрләр яза.

Г.Ибраһимов публицист, галим һәм җәмәгать эшлеклесе дә була. Аның «Мәктәптә тел һәм әдәбият укыту методикасы», «Татар теленең грамматикасы» кебек хезмәтләре хәзер дә актуальлеген югалтмаган. Күпкырлы эшчәнлеге өчен аңа 1932 нче елда Хезмәт Герое дигән мактаулы исем бирелә. Аның әсәрләре рус, казах, башкорт телләренә тәрҗемә ителә.

Г.Ибраһимовның тормышы фаҗигале була. Авыру булуга карамастан, Ялтада дәваланып яткан җиреннән, аны Казанга алып кайталар. Милләтчелектә гаепләп, төрмәгә ябалар һәм 1938 нче елда атып үтерәләр. Шулай итеп, Г.Ибраһимов та шәхес культы корбаны була.

**Сораулар**

Галимҗан Ибраһимовның әсәрләрен укыганыгыз бармы?

Аның фәнни эшчәнлеге турында нәрсәләр әйтергә мөмкин?

Хәзерге вакытта кайсы фәнни-тикшеренү институты Галимҗан Ибраһимов исемен йөртә?

**Бирем.** Герой-шагыйрь Муса Җәлил турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- сугыш кырларында;
- яшерен оешмадагы эшчәнлеге;
- “Моабит дәфтәрләре” җыентыгы.

## МУСА ҖӘЛИЛ
## (1906—1944)

Муса Җәлил 1906 нчы елның 15 нче февралендә Оренбург өлкәсе Мостафа авылында гаиләдә алтынчы бала булып дөньяга килә. Аннары аларның гаиләләре Оренбургка күчеп китә. Оренбургка күчкәч, Муса алты яшеннән үк «Хөсәения» мәдрәсәсенең башлангыч классларында укый башлый. Ул бик яшьли әдәбият белән кызыксына, 9 яшендә үк шигырьләр яза. Гражданнар сугышы елларында аның шигырьләре «Кызыл Йолдыз» исемле фронт газетасында басылып чыга.

20—30 нчы елларда Җәлилнең иҗаты тагын да үсә. Бөек Ватан сугышына кадәр үк ул татар халкының күренекле шагыйре, җәмәгать эшлеклесе булып танылa. Ул күп шигырьләр, җырлар иҗат итә. Аның «Хат ташучы», «Алтынчәч», «Җиһан», «Илдар» исемле поэмалары, күп җырлары халыкта популярлык казана.

Бөек Ватан сугышы башлану белән үк, шагыйрь Совет Армиясе сафына баса. 1941 нче елның декабрендә хәрби-политик курсларны тәмамлаганнан соң, Җәлил, өлкән политрук буларак, Волхов фронтына җибәрелә. Биредә ул «Отвага» газетасында эшли. Үзенең язган шигырьләрендә сугышчыларның героик тормышын сурәтли. 1942 нче елда, авыр яраланып, фашистлар кулына эләгә.

1945 нче елның апрелендә совет солдатлары Моабит төрмәсенең ишегалдында Җәлилнең ниндидер китап битенә язып калдырган хатын табалар һәм аны Мәскәүгә — Язучылар берлегенә — Александр Фадеевка җибәрәләр. Эзләнү, тикшеренүләр башлана. Төрмәдә Җәлил белән бергә утырган һәм шагыйрьнең соңгы айларын, көннәрен күргән хәрби әсир италияле Рениеро Ланфредини белән Бельгия патриоты Андре Тиммерманс табылалар.

Җәлил яшерен оешмага 1943 нче елның башларыннан ук кушыла, фашизмга каршы төрле юллар белән эш алып бара, «Идел-Урал» комитетында эшли. Яшерен оешма әсирләрнең кораллы восстаниесен әзерли, ләкин гестапо аны белә, һәм җәлилчеләр восстаниегә берничә көн кала кулга алыналар. 1944 нче елда Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә Дрезденда суд була. Аларны үлем җәзасына хөкем итәләр һәм Плетцензее төрмәсендә гильотинада үтерәләр. Менә алар: Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фуат Булатов, Гайнан Курмашев, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Габдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов, Фоат Сәйфелмөлеков, Әхәт Аднашев, Сәлим Бохаров.

1956 нчы алда СССР Югары Советы Президиумы Указы белән Муса Җәлилгә, Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыгы өчен, Советлар Союзы Герое исеме бирелде.

Муса Җәлилнең төрмәдә иҗат ителгән шигырьләре теркәлгән дәфтәрне «Моабит дәфтәрләре» дип йөртәләр. Дәфтәрнең беренче битләрендә шагыйрьнең концлагерьда кичергән фаҗигале тормышы сурәтләнә («Кичер, илем», «Ирек», «Кошчык»). Дәфтәрдәге шигырьләрнең күбесе, яшерен оешма ачылып, шагыйрь төрмәгә ябылганнан соң иҗат ителгән.

Туган илгә Җәлилнең ике дәфтәре кайтты. Беренчесен катлаулы юллар аша Казанга 1946 нчы елны әсир Нигъмәт Терегулов алып кайта. Икенче дәфтәрен Бельгия патриоты Андре Тиммерманс саклап кала һәм, камерадаш дусты Муса Җәлилнең васыятен үтәп, дәфтәрне 1947 нче елны Брюссельдәге Совет илчелеге аша Язучылар берлегенә җибәрә. «Моабит дәфтәрләре» — Җәлил поэзиясенең иң югары ноктасы. Бөтен дөньяга мәшһүр «Моабит дәфтәрләре» Ленин премиясенә лаек булды.

Җәлилнең мәхәббәт турында да шигырьләре күп. «Сөеклемә», «Ышанма», «Бүләгем» һәм башка шигырьләрендә ул мәхәббәтнең иң изге хис икәнлеге турында яза.

**Сораулар**

Муса Җәлилнең шигырьләре сезгә танышмы?

Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре истәлеге белән бәйле нинди урыннарны һәм чараларны беләсез?

Казанда  Муса Җәлил музеенда булганыгыз бармы?

**Бирем.** Танылган татар язучысы һәм шагыйре Фәнис Яруллин  турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- хәрби хезмәткә алынуы;
- беренче шигырь җыентыклары;
- драма әсәрләре.

## ФӘНИС ЯРУЛЛИН
## (1938 - 2011)

Фәнис Яруллин 1938 нче елда Татарстанның Баулы районында туган. Булачак язучы туган як табигатенә балачактан ук сокланып үскән.

Сугыштан соңгы елларда Фәнис Яруллинга белем алырга мөмкинлекләр булмый, чөнки аның әтисе сугышта һәлак була. Сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач, Фәнис Яруллин «Татнефть» берләшмәсендә монтер булып эшли башлый. Хәрби хезмәткә алынгач, ул укчы-радистлар әзерли торган авиация мәктәбенә эләгә һәм анда җиңел атлетика белән ныклап шөгыльләнә. Кызганычка каршы, физик күнегүләр башкарганда, ул турниктан егыла һәм имгәнә. Шул көннән бирле Фәнис Яруллин урын өстендә.

Павел Корчагин образы белән рухланган егет үзенең бөтен тормышын һәм көчен әдәбиятка багышлый. Читтән торып укып, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый, шигырьләр, хикәяләр, драма әсәрләре яза башлый. Аның китаплары әдәбият сөючеләр арасында зур уңыш казана. Төрле елларда аның «Мин тормышка гашыйк», «Аерылмас дустым» һәм башка шигырь җыентыклары басылып чыга. Республикабыз театрлары сәхнәләрендә «Әнә килә автомобиль...», «Сөембикә егет сайлый» һәм башка пьесалары куела.

1995 нче елда «Җан авазы» исемле китабы өчен Фәнис Яруллин Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Ул шулай ук Халыклар дуслыгы ордены белән дә бүләкләнә.

Фәнис Яруллинның аерым шигырьләре рус, казах, венгр, болгар, инглиз һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән.  Ул — 30 дан артык китап авторы.

**Сораулар**

Фәнис Яруллинның язмышы кайсы рус язучысының язмышына охшаш?

Сезнеңчә, тормышта авырлыкларга бирешмәс өчен, нинди булырга кирәк?

Сезнеңчә, авырлыкларны җиңү өчен, нинди сыйфатларга ия булырга кирәк?

**Бирем.** Татар милли балетына нигез салучы Фәрит Яруллин турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- композиторның балачагы;
- композиторның беренче әсәрләре;
- “Шүрәле” балетын иҗат итү.

ФӘРИТ ЯРУЛЛИН
(1914—1943)

Танылган композитор Фәрит Яруллин — татар милли балетына нигез салучы. Ул 1914 нче елда Казанда туган. Аның әтисе күренекле халык музыканты Заһидулла Яруллин булган. Кечкенә чакта ук Фәрит Яруллин әтисе кебек оста музыкант булырга теләгән. Башта аны әтисе фортепианода уйнарга өйрәткән. Соңыннан Фәрит Яруллин Казан музыка техникумында укыган. Яшь музыкант Казанның мәдәни тормышында актив катнашкан: концертларда аккомпаниатор булган, үзешчән хор белән җитәкчелек иткән.

Техникумны бетергәч, Фәрит Яруллин Мәскәү консерваториясендә укуын дәвам иткән. Бирелә ул татар опера студиясендә белем алган. Фәрит Яруллин опера студиясенә кергәндә, инде берничә җыр һәм фортепиано өчен пьеса язган була. Студиядә укыганда, ул фортепиано белән виолончель өчен соната, симфониясенең беренче кисәген, романслар яза.

1939 нчы елда Фәрит Яруллин бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның «Шүрәле» поэмасы буенча музыкаль әсәр яза башлый. Тиз арада сценарий төзелә, һәм композитор балет күренешләрен бер-бер артлы иҗат итәргә керешә. «Шүрәле» балеты 1941 нче елның августында Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә куелырга тиеш була. Ләкин 1941 нче елның июнендә Бөек Ватан сугышы башлана, һәм Фәрит Яруллин фронтка китә. 1943 нче елда лейтенант Фәрит Яруллин батырларча һәлак була.

Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты беренче тапкыр бары тик 1945 нче елда куела. Озак еллар инде әлеге әсәр Татар опера һәм балет театры сәхнәсеннән төшми. Балетны Татарстан тамашачылары да, чит ил кунаклары да яратып карыйлар.

Фәрит Яруллинның иҗат гомере кыска булса да, аның исемен халык онытмый.

**Сораулар**

«Шүрәле» балетын караганыгыз бармы?
Сез балет белән кызыксынасызмы?

Казанда нинди балет фестивале үткәрелә?Аның турынданиләр беләсез?

**Бирем.** Беренче татар хатын-кыз компохитор Сара Садыйкова турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- музыкаль белем алу;
- опера җырчысы буларак танылу;
- композиторның җәмәгать эшчәнлеге.

САРА САДЫЙКОВА
(1906—1986)

Татар халкының сөекле композиторы һәм җырчысы Сара Садыйкова 1906 нчы елда Казанда приказчик гаиләсендә туа. Балачактан ук татарның моң-җырларын ишетеп үсә, музыка коралларында уйнарга өйрәнә, әдәбият-сәнгать кешеләре белән аралаша. Казан педагогия техникумында укыган елларында концертларда, спектакльләрдә катнаша. Укуга омтылыш, сәнгатькә мәхәббәт 16 яшьлек кызны Мәскәүгә алып килә. Ул Мәскәү консерваториясендә укый.

XX гасырның 20—30 нчы елларында Сара Садыйкова җырчы буларак танылa. Күп кенә татар операларында («Сания», «Эшче», «Качкын», «Илдар») төп партияләрне башкара, мәшһүр «Башмагым», «Зәңгәр шәл» спектакльләрендә уңышлы чыгыш ясый, рус һәм Көнбатыш Европа музыкаль классикасын халыкка җиткерүгә дә үзеннән өлеш кертә.

Сара Садыйкова күп кенә шагыйрьләр, артистлар, рәссамнар белән иҗади дуслыкта яшәде, гомеренең ахырына кадәр халык белән очрашып торды, кичәләрдә чыгышлар ясады. Моң-җырлары, тырыш хезмәте өчен халык үзенең талантлы кызын «Сары Сандугач» дип атады. Сара Садыйкова — Татарстанның халык артисткасы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

**Сораулар**

Сез хатын-кыз композиторлардан тагын кемнәрне беләсез?
Яхшы җырчыны халык нинди кош белән чагыштыра?
Яраткан композиторыгыз бармы?

**Бирем.** Беренче татар профессиональ рәссамы Бакый Урманче турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- һөнәри белем алу;
- рәссамның беренче картиналары;
- тарихи шәхесләрнең портретлары.

## БАКЫЙ УРМАНЧЕ
## (1897—1990)

Татарстанның халык рәссамы, Россиянең атказанган һәм халык рәссамы, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Бакый Урманче — татар рәсем һәм сынлы сәнгатен профессиональ дәрәҗәгә күтәргән зур осталарның берсе. Ул элекке Казан губернасы Тәтеш өязе (хәзерге Буа районында) дөньяга килә. 1907—1914 нче елларда Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала, аннары авылда укытучы булып эшли. Беренче бөтендөнья сугышы чорында армиягә алына: Казахстанга әләгеп, андагы Австрия хәрби әсирләреннән рәсем сәнгатенә өйрәнә.

Башта Б.Урманче Казан сәнгать училищесында укый. Аннары Югары дәүләт сәнгать-техника остаханәсенә укырга кереп, аны тәмамлый. Казанда, Мәскәүдә, Донбасста, Башкортстанда эшләп, тормыш тәҗрибәсе туплый, актив иҗат эше белән шөгыльләнә. Бу чорда Б.Урманче көнкүреш һәм портрет жанрында күбрәк эшли һәм «Самавыр янында», «Җилкәнле көймәдә йөзү» кебек картиналарын иҗат итә.

Аннары Алма-Ата, Сәмәрканд, Ташкент шәһәрләрендә яши. Ул рәсем сәнгате, графика, китап иллюстрациясе, театр декорациясе, сынлы сәнгать, архитектура өлкәсендә зур иҗади казанышларга ирешә. Шулай ук Казахстан һәм Үзбәкстан сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертә.

1958 нче елда рәссам Казанга кайта. Аның бу елларда иҗат иткән әсәрләреннән «Кышкы кояш», «Казан чите», «Юкәләр чәчәк ата», «Ибн Фадланның Болгарга килүе» һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

Б.Урманче бу чорда тарихи шәхесләр, мәгърифәтчеләр, әдәбият һәм сәнгать вәкилләре, ялкынлы революционерларның скульптур портретларын иҗат итә, аларны мәңгеләштерә. К. Насыйри, Г.Тукай, Ш.Мәрҗани, Г.Кариев, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, Г.Ибраһимов, Н.Исәнбәт, М.Җәлил, Н.Җиһанов портретлары аша бу шәхесләрнең рухи байлыгын һәм матурлыгын күрсәтүгә ирешә.

Б.Урманче милләтебез һәм республикабыз тормышы белән тыгыз бәйләнештә яшәде. Хәзерге вакытта аның әсәрләре Халыкара күргәзмәләрдә күрсәтелә, шәхси күргәзмәләре дә оештырыла.

**Сораулар**

Сезнең Бакый Урманче музеенда булганыгыз бармы?
Танылган татар рәссамнарыннан тагын кемнәрне атый аласыз?
Сезнеңчә, рәссамнарга нинди сыйфатлар хас?

**Бирем.** Беренче татар профессиональ рәссамы Бакый Урманче турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- һөнәри белем алу;
- артист иҗат иткән образлар;
- Әлмәндәр ролен башкару.

## ШӘҮКӘТ БИКТИМЕРОВ
## (1928 - 2012)

Татарстанның һәм СССРның халык артисты, Константин Станиславский исемендәге һәм Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Шәүкәт Биктимеров иҗат иткән образлар арасында Әлмәндәр карт аерым урын тота. Хәтта күпләр: «Нихәл, Әлмәндәр бабай?» — дип мөрәҗәгать итә торган булганнар икән аңа.

Шәүкәт Хәсән улы Биктимеров 1928 нче елда Саба районының Миңгәр авылында туа. Аның әтисе укытучы була һәм төрле авылларда балаларга белем биреп йөри, шуңа күрә Шәүкәт тә күп авылларны күрә, төрле мәктәпләрдә укый.

1945 нче елда Шәүкәт Казан театр училищесына укырга керә һәм, аны тәмамлагач, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли башлый. Армиядә хезмәт итеп кайткач, 1953 нче елда ул яңадан театрда эшен дәвам итә.

Шәүкәт Биктимеров — йомшак күңелле, мөлаем, гадел кеше иде. Ул сәхнәдә тудырган образлар да кешеләрне гел яхшылык кылырга гына өйрәтә. Шәүкәт абый — бәхетле язмышлы артист. Ул башкарган рольләрне санап бетерү мөмкин түгел. Танылган драматургларның төрле әсәрләрендә ул уйнаган рольләрне тамашачылар яхшы хәтерли. Алар арасында зурлары да, кечкенәләре дә бар. Туфан Миңнуллин пьесасы буенча Марсель Сәлимҗанов куйган «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле исә аңа зур уңыш алып килә. Гадел, тырыш, тормыш сөюче, зирәк Әлмәндәр образы өчен Ш.Биктимеровка Россия Федерациясенең К. Станиславский исемендәге Дәүләт бүләге бирелә.

**Сораулар**

Сезнең яраткан артистыгыз кем?

Сезнең нинди спектакль карыйсыгыз килә һәм ни өчен?

Театр сәнгате белән кызыксынасызмы?

**Бирем.** Атаклы татар рәссамы Харис Якупов турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- рәссамның иң танылган картиналары;

- иң яхшы хезмәтләренең күргәзмәләрдә күрсәтелүе;
- фронтта ясалган рәсемнәре.

## ХАРИС ЯКУПОВ
## (1919 - 2010)

Россиянең һәм Татарстанның халык рәссамы, СССРның Дәүләт премиясе лауреаты Харис Якуповның исеме күпләргә таныш, чөнки үзенең озын иҗат юлында рәссам 300 дән артык картина иҗат иткән. Алар арасында үз масштаблары белән күпләрне таң калдырырлык 20 полотно һәм 200 дән артык рәсем бар.

Харис Якупов Казанда туа һәм анда сәнгать училищесын тәмамлый. Күренекле рәссамга фронт кырларында да булырга туры килә. Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен ул II дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм Кызыл Йолдыз орденына лаек була.

Рәссамга Почет Билгесе ордены «Татарстан АССР оешу турында декретка кул кую» исемле картинасы өчен бирелә. Харис Якуповның иң яхшы хезмәтләре Дәүләт Третьяков галереясында, Россиянең Шәрык мәдәнияте музеенда, Татарстан Республикасының Сынлы сәнгать музеенда саклана. Бу рәсемнәр Финляндиядә, АКШта, Кытайда, Франциядә, Монголиядә, Венгриядә, Болгариядә һәм башка бик күп илләрдә күргәзмәләрдә булдылар.

Харис Якупов үзенең картиналарында Татарстанның кешеләрен, туган як табигатен һәм байлыгын тасвирлый. Аның фронтта ясаган рәсемнәре аеруча кызыклы, чөнки рәссам Сталинград, Курск дугасы, Львов, Польша, Германия, Чехословакияне азат итүдә үзе катнаша һәм фронт окопларында рәсемнәрен ясый.

Рәссам Татарстан китап нәшрияты белән тыгыз хезмәттәшлек итә, кырыклап китап бизи. “Татар халык әкиятләре” китабына (1957) эшләнгән иллюстрацияләр өчен ул Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Казан Кремлендә ачылган Сәнгать галереясында Харис Якупов иҗатына да урын бирелгән. Биредә рәссамның 15 зур хезмәте һәм фронтта иҗат иткән рәсемнәре, шулай ук графикасы урын алган.

**Сораулар**

Татар рәссамнарыннан кемнәрне беләсез?
Харис Якуповның картиналарын күргәнегез бармы?
Сынлы сәнгатьне үстерү максатыннан, Татарстанда нинди эшләр башкарыла?

**Бирем.** Татар опера җырчысы Хәйдәр Бигичев турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- җырчының студент еллары;
- татар опера сәнгатен үстерүдәге роле;
- җырчының үзенчәлекле тавышы.

ХӘЙДӘР БИГИЧЕВ
(1949 – 1998)

Хәйдәр Бигичев опера арияләрен дә, эстрада җырларын да, халык көйләрен дә бердәй осталык белән башкаручы талантлы артист иде.

Ул 1949 елның 16 нчы июнендә Горький (хәзерге Түбән Новгород) өлкәсенең Чүмбәли авылында туа. Студент елларыннан ук тынгысыз җырчы репертуарын Европа, рус, татар композиторларының классик музыкасы белән баета. Ул татар халык җырларын, музыка теориясен һәм тарихын, төрле вокал мәктәпләренең үзенчәлеген өйрәнә. Дөньякүләм бөек җырчылар калдырган язмаларны тыңлап, алардан үрнәк ала.

Х.Бигичев татар опера сәнгатен үстергә зур өлеш кертә. Ул татар композиторларының сәхнәдә куелган барлык әсәрләрендә төп партияләрне башкара. Мәсәлән, “Алтынчәч”, “Җәлил”, “Самат”, “Кара йөзләр” опералары һ.б. Рус һәм чит классик опера спектакльләрендә Хозе (“Кармен”), Германн (Пика дамасы”), Отелло (“Отелло”) партияләрен дә җырчы сокландыргыч дәрәҗәдә башкара. Белгечләр әйтүенчә, Х.Бигичев иҗат иткән Отелло образы - илебез опера сәнгате өчен зур казаныш.

Х.Бигичев - дөньяда сирәк очрый торган тавышлы җырчыларның берсе. Безнең татар опера сәнгате тарихында аныкы кебек башка тавыш юк. Ул көчле яңгырашлы тенор җырчы.

Композитор Бату Мөлековның “Каһәрләнгән мәхәббәт” операсында төп рольне башкарган өчен Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Аңа Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты исемнәре бирелә.

Хәйдәр Бигичев опера һәм җыр сәнгатендә бәяләп бетермәслек музыкаль мирас калдырды.

**Сораулар**

Сез опера сәнгате белән кызыксынасызмы?
Татар опера һәм балет театрында булганыгыз бармы?
Күренекле опера җырчыларыннан кемнәрне беләсез?

**Бирем.** Күренекле татар телчесе Мирфатыйх Зәкиев турында сөйләгез. Сөйләгәндә, түбәндәге мәгълүматлар турында әйтергә онытмагыз:

- балачакта хуҗалык эшләрендә ярдәм итү;
- югары белем алу;

- галимнең хезмәтләре һәм шәкертләре.

## МИРФАТЫЙХ ЗӘКИЕВ
## (1928)

Татар тел белеме өлкәсендә зур уңышларга ирешкән галим, академик Мирфатыйх Зәкиевич Зәкиевнең исеме бөтен дөньяга билгеле.

Ул 1928 нче елда Ютазы районында туган. Мәктәптә укыганда, җәен колхозда эшләгән, көтү көткән, ат караган, тимерче дә булган. Мәктәпне бетергәч, ул Казан дәүләт университетында, татар филологиясе бүлегендә укыган. Укуын тәмамлаганнан соң, Мирфатыйх Зәкиев татар теле кафедрасында эшкә кала. Башта өлкән укытучы, аннары доцент, ә 60 нчы елларда татар теле кафедрасы мөдире булып эшли башлый. Докторлык диссертациясен яклагач, ул профессор дәрәҗәсенә ия була.

Күп еллар М.З.Зәкиев Казан педагогика институтының ректоры булып эшли, ә соңыннан Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән җитәкчелек итә. М.З.Зәкиев — Татарстан Фәннәр академиясенең академик-секретаре. 1992 нче елда Англиянең Халыкара биографик үзәге аны «Халыкара ел кешесе» дип игълан итте. 1993 нче елда Америкадагы Халыкара биографик институтның конкурсы буенча дөньяда иң күренекле җитәкчеләрнең берсе дип танылды.

М.З.Зәкиев — 30 дан артык фәннәр кандидатының хөрмәтле остазы да. Аның шәкертләре арасында профессорлар Ф.С.Сафиуллина, Г.Ф.Саттаров һәм башкаларны атарга мөмкин. Алар Татарстанда, Башкортстанда, Россиянең күп кенә өлкәләрендә һәм башка бик күп төбәкләрдә эшлиләр.

Академик М.З.Зәкиев — күпсанлы фәнни хезмәтләр, монографияләр, мәктәп дәреслекләре авторы. Өч томлы «Татар грамматикасы» өчен, ул Татарстан Республикасының Дәүләт премиясенә лаек булды.

Гомумән әйткәндә, Мирфатыйх Зәкиев — татар тел белеме үсешенә искиткеч зур өлеш керткән галим.

**Сораулар**

Татар тел белеме үсешенә зур өлеш керткән галимнәрдән тагын кемнәрне беләсез?

Галим булу өчен, нинди сыйфатлар мөһим?

Татар телен өйрәнү өчен, нәрсәләрдән файдаланасыз?

# ИКЕНЧЕ БҮЛЕК. ДИАЛОГИК СӨЙЛӘМГӘ ӨЙРӘТҮ

**Бирем.**

Сез татар театры кассасына билет алырга килгән тамашачы ролен башкарасыз һәм билет сатучы белән әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында
- билет сатучыдан театрның репертуары турында сорагыз;
- көндезге спектакльләрнең булу- булмавын белешегез;
- театрда үзеңне тоту кагыйдәләрен ачыклагыз;
- яшьләрнең кайсы спектакльләргә йөрүләре белән кызыксыныгыз;
- билет сатучының тәкъдимен кабул итегез яки кире кагыгыз.

ТЕАТРДА

**Үрнәк диалог.**

**Тамашачы**: Исәнмесез!
**Кассир**: Хәерле көн!
**Тамашачы**: Гафу итегез, сез миңа ярдәм итә алмассызмы?
**Кассир**: Әйе, тыңлыйм Сезне.
**Тамашачы**: Мин Казанга күптән түгел килдем. Берәр кызыклы спектакль карарга телим. Сез миңа кайсы спектакльгә барырга киңәш итәрсез?
**Кассир**: Театрыбызның репертуары төрле. Сезгә нинди әсәрләр күбрәк ошый: драммамы, комедияме, әллә мелодрамалармы?
**Тамашачы**: Миңа барысы да ошый. Минем татар мохитен сурәтләгән спектакль карыйсым килә. Казанда минем кебек яшьләр нинди спектакльләргә йөрергә яраталар?
**Кассир**: Яшьләр төрле спектакльләргә йөриләр. Классик спектакльләрдән “Зәңгәр шәл” не карарга була. Заманча тамаша карыйсыгыз килсә, “Әле кичә генә җәй иде”, “Мәхәббәт FM” пьесаларын тәкъдим итәм.
**Тамашачы:** Спектакльләр кичен генә буламы?
**Кассир**: Юк, шимбә һәм якшәмбе көннәрендә көндезге спектакльләр дә була. Сез кайсы көнне театрга килергә телисез?
**Тамашачы**: Мин әлегә төгәл белмим. Без дустым белән килергә уйлыйбыз. Минемчә, ял көннәре яхшырак булыр. Ә сезнең театрда тамашачылар өчен махсус кагыйдәләр бармы, яки алар башка театрлардагычамы? Спектакль барышында фотога, видеога төшерергә һәм телефоннан сөйләшергә ярамый...
**Кассир**: Бездә дә шул ук кагыйдәләр.
**Тамашачы**: Сез әйткән спектакльләр кайчан була? Аларга билетлар бармы әле?
**Кассир**: “Зәңгәр шәл” спектакле шимбә көнне кичен, ә “Мәхәббәт FM” спектакле сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә була. Әлегә билетлар бар. Сезгә кайсы көнгә ничә билет кирәк?

**Тамашачы**: Ике билет кирәк, ләкин миңа дустым белән киңәшергә кирәк. Мәгълүмат өчен зур рәхмәт сезгә. Дустым белән сөйләшкәч, билет алырга килермен.
**Кассир**: Яхшы.
**Тамашачы**: Игътибарыгыз өчен Сезгә зур рәхмәт Әлегә сау булыгыз!
**Кассир**: Сау булыгыз! Хәерле юл!

**Бирем.**
Сез беренче тапкыр Казанга килгән турист ролен башкарасыз һәм экскурсовод белән әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында
- экскурсоводтан Казан Кремлендә урнашкан истәлекле урыннар турында сорагыз;
- андагы музейларар турында белешегез;
- туристларның яраткан урыннарын ачыклагыз;
- күренекле шәхесләргә багышланган музейлар белән кызыксыныгыз;
- шәһәрнең тарихи урыннарына соклануыгызны белдерегез.

## КАЗАН БЕЛӘН ТАНЫШУ

**Үрнәк диалог.**

**Турист**: Хәерле көн!
**Экскурсовод**: Хәерле көн!
**Турист**: Сезгә мөрәҗәгать итәргә мөмкинме? Мин Казанда беренче тапкыр. Нинди күркәм шәһәр икән Казан!!! Бигрәк тә шәһәрнең тарихи үзәге искиткеч иатур. Сез миңа кайсы урыннарда булырга тәкъдим итәрсез?
**Экскурсовод**: Әлбәттә, беренче чиратта, Кремль белән танышырга кирәк, төп истәлекле урыннар шунда урнашкан.
**Турист**: Минем Казан Кремле турында укыганым бар, хәзер күрәсем килә инде шул урыннарны. Анда нинди дә булса музейлар да бармы? Казан Кремлендә Эрмитаж музееның филиалы эшли дип ишеткән идем.
**Экскурсовод**: Әйе, тарихи манаралардан, мәчет һәм чиркәүләрдән тыш, анда музейларга да керергә мөмкин. Сез сәнгать музейларында, әллә тарихи музейларда булырга яратасызмы?
**Турист**: Миңа барысы да кызык. Минем Татарстанның тарихына караган күргәзмәләр белән дә, күренекле татар рәссамнарының иҗаты белән дә танышасым килә. Казанда туристлар нинди музейларда булырга яраталар?
**Экскурсовод**: Казан Кремле каршында урнашкан Татарстанның Милли музее туристлар өчен бик кызыклы. Моннан тыш, Сынлы сәнгать музеенда да туристларны еш күрергә мөмкин.

**Турист**: Ә менә атаклы шәхесләрнең музейларына килгәндә, кайсыларына барырга киңәш итәр идегез? Күренекле татар язучылары, рәссамнары, композиторларынң музейлары бармы?
**Экскурсовод**: Казан кунаклары Горький музеен, Салих Сәйдәшев музеен, Бакый Урманче музеен бик яратып карыйлар. Сезнең бу музейларда буласыгыз киләме?
**Турист**: Вакытым калса, аларны да карармын дип уйлыйм. Мин Казанда бер атна гына булам. Ә карар урыннар шактый күп. Борынгы Болгарга да барып кайтасым килә. Анда хәзер бик матур дип язалар. Чыннан да шулаймы?
**Экскурсовод**: Барып күргәч, чыннан да шулай икән диярсез.
**Турист**: Сез хаклы. Казан урамнары буйлап йөргәндә, мин шәһәрегезнең матурлыгына сокланам. Укыганым булды бу турыда: Универсиада, Су спорты буенча дөнья чемпионаты, халыкара фестивальләр.
**Экскурсовод**: Соңгы елларда шәһәребез бик нык үзгәрде, матурланды, чөнки зур халыкара чаралар үткәрелә. Шуңа күрә дә Казанга килүче туристларның саны елдан-ел артта.
**Турист**: Барлык мәгълүмат өчен сезгә бик тә рәхмәтлемен. Бер килүдә генә барысын да карап бетереп булмас, әмма сез әйткән урыннарда булырга тырышырмын.
**Экскурсовод**: Уңышлар Сезгә.
**Турист**: Игътибарыгыз өчен Сезгә зур рәхмәт! Сау булыгыз!
**Экскурсовод**: Сезгә дә күңелле сәяхәт телим! Сау булыгыз!

**Бирем.**
Сез телләр өйрәнүгә багышланган фәнни конференциядә чыгыш ясаучы укучы ролен башкарасыз һәм укытучыгыз белән әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында
- укытучыгыздан конференцияне үткәрү тәртибе турында сорагыз;
- үзегез туплаган мәгълүмат турында әйтегез;
- презентация ясауның кирәклеген белешегез;
- чыгыш ясаганнан соң, катнашучыларга сораулар бирелү-бирелмәвен ачыклагыз;
- киләчәктә тәрҗемәче булырга теләвегезне әйтегез.

ТЕЛЛӘР ӨЙРӘНҮ

**Үрнәк диалог.**

**Укучы**: Исәнмесез! Керергә ярыймы?
**Укытучы**: Рәхим итегез! Керегез! Хәерле көн!

**Укучы**: Киләсе атнада мин укучылар конференциясендә чыгыш ясарга әзерләнәм. Минем шундый чарада әле беренче генә катнашуым. Шуңа күрә конференцияне үткәрү тәртибе турында беләсем килә. Сез миңа аңлата аласызмы?
**Укытучы**: Яхшы. Башта конференциядә катнашучыларның барысы да теркәлү үтә, аннары аларны оештыручылар сәламлиләр. Шуннан соң укучылар төрле секцияләргә таралалар.
**Укучы:** Анда һәр укучыга чыгыш ясау өчен күпме вакыт бирелә?
**Укытучы:** 5-7 минут вакыт бирелә. Сез җитәрлек материал тупладыгызмы?
**Укучы**: Минем чыгышым татар теленә өйрәтү проблемасына багышланган. Мин фәнни хезмәтләр белән таныштым, төрле дәреслекләрне, сөйләүлекләрне карап чыктым, дистанцион курслар турында да материал таптым. Җитәрлек дип уйлыйм. Анда презентация кирәк буламы, сезнеңчә?
**Укытучы**: Әйе, презентация булганда, чыгыш өчен югары баллар куела. Призлы урын яуларга мөмкин.
**Укучы:** Алайса миңа да презентация әзерләргә кирәк. Презентациягә телләр турында мәкальләр, шулай ук күренекле шәхесләрнең телләр белүнең кирәклеге турындагы сүзләрен дә кертергә кирәк дип саныйм.
**Укытучы:** Бик яхшы. Алар чыгышыгызны баетыр. Чыгышыгыз ничә минутлык, укып карадыгызмы?
**Укучы**: Мин берничә тапкыр докладымны укып карадым. 5-6 минутлык булыр. Чыгыш ясаганнан соң, сораулар да бирәләрме?
**Укытучы**: Фәнни докладтан соң, гадәттә, һәрвакыт сораулар бирелә.
**Укучы:** Алар жюри тарафыннан гына бирeләме, әллә башка чыгыш ясаучылардан да булырга мөмкинме?
**Укытучы:** Аларга да сорау бирергә ярый, ә кайвакыт сораулар булмаска да мөмкин. Ә менә алар булса, димәк, сезнең чыгышыгыз тыңлаучыларда кызыксыну уяткан. Ә сез ник нәкъ шушы конференциядә катнашырга уйладыгыз?
**Укучы**: Мин инде берничә ел телләр белән кызыксынам. Мәктәптә рус, инглиз, татар телләрен өйрәнәм. Ә быел итальян телен өйрәнә башладым курсларда. Бу тел миңа бик ошый. Шул телләрне чагыштыру, алардагы аермаларны һәм охшаш якларын табу шундый кызык. Әллә нәрсәләр беләсең!!!! Бүгенге көндә телләр белү бигрәк тә кирәк, чөнки төрле илләр үзара аралашалар, хезмәттәшлек итәләр. Телләр белгән кешегә яхшы эш табу да җиңелрәк.
**Укытучы**: Дөрес, телләр белү – зур байлык ул. Сезнең киләчәктә кем буласыгыз килә?
**Укучы**: Мин тәрҗемәче булырга хыялланам. Яңа кешеләр белән танышу һәм аралашу миңа бик кызык. Аннары төрле илләрдә булырга мөмкин. Гаиләбездә дә тәрҗемәчеләр бар. Әтием зур фирмада тәрҗемәче булып эшли. Ул дүрт тел белә. Әбием дә тәрҗемәче булып эшләгән. Ул китаплар тәрҗемә иткән,

нәшриятта эшләгән, хәзер пенсиядә инде. Ул үзенең эше турында миңа шундый кызык итеп сөйли.
**Укытучы**: Алайса, якын туганнарыгыздан үрнәк алырга мөмкин. Сез дә әбиегез һәм әтиегез кебек яхшы тәрҗемәче булырсыз.
**Укучы**: Рәхмәт яхшы сүзләрегез өчен, мин дә бик ышанам. Соңгы вакытта безнең шәһәрдә төрле халыкара чаралар үткәрелә. Спорт ярышлары, фестивальләр. Аларны оештыру өчен, тәрҗемәчеләр дә бик кирәк. Чит ил кунакларын каршылау, аларны озатып йөрү тәрҗемәчеләрнең эше бит.
**Укытучы**: Әйе, килешәм, тәрҗемәчеләрне әзерләүгә хәзер зур игътибар бирелә.
**Укучы**: Тырышып укысам, киләчәктә мин дә тәрҗемә белән шөгыльләнермен. Файдалы киңәшләрегез өчен бик зур рәхмәт.
**Укытучы**: Уңышлы чыгыш ясаугызны телим.
**Укучы**: Сез мине шатландырдыгыз. Сау булыгыз!
**Укытучы**: Сау булыгыз!

**Бирем.**

Сез Шигырь бәйрәменә килгән тамашачы ролен башкарасыз һәм яңа танышыгыз белән әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында
- танышыгызның кайдан булуын ачыклагыз;
- шигырь язу-язмавын белешегез;
- шигърият белән кызыксынуы турында сораштырыгыз;
- яраткан шагыйрьләре турында сорагыз;
- танышыгызга алга таба электрон почта аша аралашырга тәкъдим итегез.

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

**Үрнәк диалог.**

**Тамашачы**: Исәнмесез!
**Таныш**: Хәерле көн!
**Тамашачы**: Таныш булыйк. Мин – Азат/Алсу. Ә Сез кем буласыз?
**Таныш**: Ә мин – Сәрия/Сәлим.
**Тамашачы**: Мин Казаннан, унберенче сыйныфта укыйм. Ә Сез кайдан?
**Таныш**: Мин Арчадан, педагогика колледжында беренче курста укыйм. Сез шигырьләр тыңларга яратасызмы?
**Тамашачы**: Бик яратам. Үзем дә шигырьләр язам. Кечкенә чагымда әнием белән әбием миңа татар, рус шигырьләре укыйлар иде. Аларның күбесен яттан белә идем. Хәзер дә шигырьләр ятлыйм һәм төрле концертларда, кичәләрдә сөйлим. Ел саен Шигырь бәйрәменә килеп, яңа кешеләр белән танышам, аралашам. Ә Сез иҗат белән шөгыльләнәсезме? Шигырь язу белән мавыкмыйсызмы?

**Таныш**: Юк, үзем шигырьләр язмыйм, бары тик укырга яки тыңларга гына яратам.
**Тамашачы:** Яраткан шагыйрьләрегез бармы?
**Таныш**: Әйе, бар. Татар шагыйрьләреннән миңа аеруча Хәсән Туфан иҗаты ошый. Рус әдипләреннән Вадимир Маяковскийның иҗаты миңа бик якын. Ә Сезгә кемнәрнең иҗаты ошый?
**Тамашачы**: Мин алай төгәл генә әйтә алмыйм. Миңа күп шагыйрьләрнең иҗаты ошый. Яшь шагыйрьләрнең әсәрләрен дә укырга яратам. Шулай да классик шагыйрьләрдән Фәнис Яруллинны аерып әйтер идем. Укытучыбыз безне татар теле дәресләрендә шигъриятне аңларга, яратырга өйрәтә. Безнең сыйныф укучылары "Шигъри Сабантуй" конкурсында да еш катнашалар, призлы урыннар алалар. Ә сездә шундый чаралар үткәреләме?
**Таныш**: Бездә дә әдәби кичәләр үткәрелә, танылган татар шагыйрьләре, яшь авторлар белән иҗади очрашулар уздырыла.
**Тамашачы**: Сезнең белән танышуыма мин бик шат. Шигырь бәйрәме күп кешеләрне очраштыра, таныштыра, дуслаштыра. Мин дә монда яңа дуслар табам, аннары ел дәвамында без Интернет аша хат язышабыз, шигъри яңалыклар турында фикер алышабыз, төрле кичәләрдә очрашабыз. Сез миңа электрон адресыгызны бирә аласызмы? Мин Сезгә үземнекен хәзер язып бирәм.
**Таныш**: Яхшы, миңа шундый аралашучан кешеләр ошый. Сез миңа, ә мин Сезгә яңа китаплар турында хәбәр итеп торырбыз. Интернет безгә күп мөмкинлекләр бирә.
**Тамашачы**: Минемчә, бүгенге бәйрәм бик күңелле узды. Кеше дә күп иде. Бу бик тә куандыра. Яшьләрнең шигърият белән кызыксынулары да бик мөһим. Бәйрәмнән соң да аралашып торырбыз.
**Таныш**: Яхшы.
**Тамашачы**: Ярый, бәйрәм ахырына якынлаша. Сау булыгыз!
**Таныш**: Сау булыгыз! Киләсе очрашуларга кадәр!

**Бирем.**

Сез туган көн бәйрәменә кунаклар каршы алырга әзерләнгән бала ролен башкарасыз һәм әниегез белән әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында
- әниегезгә котлау сүзләре өчен рәхмәт белдерегез;
- әниегезнең нәрсәләр пешерәсе килгәнен ачыклагыз;
- яшьләрнең нинди ризыклар ашарга яратулары турында әйтегез;
- әниегезгә нинди ярдәм кирәклеген белешегез;
- табынга нәрсәләр куелачагы турында сорагыз.

ТУГАН КӨН БӘЙРӘМЕ

**Үрнәк диалог.**

**Бала**: Хәерле иртә, әнием!
**Әни**: Хәерле иртә, балам! Туган көнең белән котлыйм! Бәхетле бул!
**Бала**: Рәхмәт, әнием. Бүген мин шундый бәхетле! Туган көнемә якын дусларым килә. Мин алар белән рәхәтләнеп күңел ачармын! Ә нәрсәләр әзерлибез аларга?
**Әни**: Әйдә, уйлашыйк. Дусларың нәрсә яраталар соң?
**Бала**: 0-о-о, аларга син пешергән һәр ризык ошар дип уйлыйм. Алар бигрәк тә токмач ашы, өчпочмак, бәлеш яраталар. Тавык кыздырырга мөмкин. Мин берничә төрле салат ясармын. Чәйгә баллы ризык алырбыз. Тагын нәрсәләр кирәк була соң?
**Әни**: Алайса, без токмач ашы белән өчпочмак пешерик. Яшьләр тагын нәрсәләр ашарга яраталар әле?
**Бала**: Аларның кайберләре татар ашларын да ярата, ләкин пицца яки роллардан башка бәйрәм өстәлен күз алдына китерә алмый. Шуңа күрә заказ бирик.
**Әни**: Анысын үз өстеңә ал инде, балам. Кая заказ бирсәк, яхшырак булуын беләсеңдер бит.
**Бала:** Әйе, хәзер бер дустыма шалтыратып белешәм дә заказ бирәм. Әни, сиңа тагын нинди ярдәм кирәк булачак?
**Әни**: Табын әзерләшергә булышырсың. Башта өстәлгә матур эскәтер җәяргә кирәк.
**Бала**: Яхшы, әнием, хәзер мин иң матур эскәтерне сайлап алам. Аннары һәр кунакка өлеш тәлинкәләре, чәнечке, пычак, калак куеп чыгам. Тагын нәрсәләр куярга кирәк була?
**Әни**: Өстәлгә алма, әфлисун, виноград куябыз. Алар өчен махсус вазалар бар.
**Бала**: Аңладым. Хәзер эшлим. Ничә урынга куябыз, әни?
**Әни**: Өч урынга кирәк булыр, кеше күп бит. Ничә кеше чакырдың?
**Бала**: Дусларым – 10 кеше. Әти белән син, әбием һәм мин үзем. Димәк, табын артында барлыгы 14 кеше булабыз. Әни, өстәлгә чәчәкләр дә куябызмы?
**Әни**: Ярар, куярсың.
**Бала**: Ах! Менә нинди матур табын булды, әни! Кара әле!
**Әни**: Әйе, чыннан да, бик матур булган! Рәхмәт сиңа, балам!

**Бирем.**

Сез җиңел атлетика буенча спорт секциясенә язылырга килгән укучы ролен башкарасыз һәм тренер белән әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында
- җиңел атлетика буенча секция булу-булмавын сорагыз;
- тренерга әлеге спорт төренең сезгә ошавын аңлатыгыз;
- яшь спортчыларның ярышларда катнашуын ачыклагыз;
- яшьләрнең кайсы спорт төрләренә күбрәк игътибар бирүләре белән кызыксыныгыз;

- тренерның  тәкъдимен кабул итегез яки кире кагыгыз.

## СПОРТ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНҮ

**Үрнәк диалог.**

**Укучы**: Хәерле кич! Керергә ярыймы?
**Тренер**: Әйе, рәхим итегез! Керегез. Сез кем буласыз?
**Укучы**: Гафу итегез, мин спорт секциясенә язылырга килдем. Сез миңа ярдәм итә аласызмы?
**Тренер**: Әйе, тыңлыйм Сезне. Кайсы секциягә барасыгыз килә?
**Укучы**: Минем җиңел атлетика белән шөгыльләнергә телим. Сезнең Спорт сараенда андый секция бармы?
**Тренер**: Әлбәттә, бар. Бездә төрле секцияләр эшли.
**Укучы**:  Минем ни өчен бу спорт төрен  сайлавым сезгә кызыктыр бәлки. Беләсезме, миңа күп спорт төрләре ошый. Телевизордан хоккей, чаңгы ярышларын, биатлон карарга яратам. Ләкин үземнең йөгерү белән шөгыльләнеп карыйсым килә. Минем әнием яшь чагында бик яхшы йөгерүче булган, шәһәр һәм республика беренчелегендә җиңүләр яулаган. Бәлки шуңадыр мин бу спорт төрен якын күрәм. Сездә спорт секцияләрендә шөгыльләнүчеләр ярышларда катнашалармы??
**Тренер**: Әлбәттә. Бездә көчле спортчылар күп. Алар төрле ярышларда призлы урыннар алалар.
**Укучы:** Тагын кайсы секцияләргә балалар күп йөри? Кайсы спорт төрләре яшьләр арасында бик популяр?
**Тренер**:  Волейбол, баскетбол, гимнастикага йөрүчеләр ел саен күп була. Сез кайсы көннәрне йөрергә  телисез?
**Укучы**: Миңа сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәре уңайлы булыр иде, чөнки ул көннәрне дәресләрем азрак. Минем дустымның да йөрисе килә. Аңа да шушы көннәр уңайлы. Ә дәресләр сәгать ничәдә башлана һәм ничә сәгать дәвам итә?
**Тренер**: Кичке биштә башлана һәм ике сәгать дәвам итә.
**Укучы**: Сез әйткән вакыт безгә туры килә. Без бу вакытта йөрергә риза.
**Тренер**: Яхшы, сөйләштек, чәршәмбе көнне икегез дә килерсез. Спорт киемнәрен  онытмагыз.
**Укучы**: Сезгә барысы өчен дә рәхмәт әйтәсем килә.
**Тренер**:  Исән-сау булыгыз.

**Бирем.**

Сез туристлык агентлыгында эшләүче хезмәткәр ролен башкарасыз һәм сезгә мөрәҗәгать иткән клиент  белән әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында
- клиенттан җәйге ялның кайчан булуын сорагыз;

- барырга теләгән илләр һәм шәһәрләр  турында белешегез;
- туристларның яраткан урыннары турында хәбәр итегез;
- юллама сатып алу өчен, файдалы киңәшләр бирегез;
- клиентың яңадан сезгә килүен сорагыз.

## СӘЯХӘТКӘ ЧЫГУ

**Үрнәк диалог.**

**Хезмәткәр**: Хәерле көн! Рәхим итегез!
**Клиент**: Рәхмәт! Хәерле көн!
**Хезмәткәр**: Җәйге ялга әзерләнүегезгә без бик шатбыз. Бездә төрле вакытка юллама алыпга мөмкин.  Ялыгыз кайсы айда булачак?
**Клиент**: Ялым июль аенда булыр дип өметләнәм.
**Хезмәткәр**: Әйдәгез, башта кайда ял итәргә теләвегезне ачыклыйк. Гадәттә Сез Россиядә ял итәсезме, әллә чит илләрдә булырга яратасызмы? Без сезгә төрле урыннарны тәкъдим итә алабыз.
**Клиент**: Яхшы, рәхмәт. Миңа Россия буйлап сәяхәт итү дә, чит илләрдә булу да ошый.
**Хезмәткәр**:  Россиянең кайсы шәһәрләрендә булдыгыз? Сезгә кайсы урыннар аеруча ошады?
**Клиент**: Әлбәттә, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта булдым, аннары Калининградта, Себердә һәм Уфада экскурсияләрдә булырга туры килде. Иң ошаган шәһәр – Санкт–Петербург.
**Хезмәткәр**: Ә менә Казанны күрәсегез киләме? Хәзер бу шәһәр Россиядә  иң матур шәһәрләрнең исемлегенә керә. Елдан-ел Казанга килүче туристларның саны арта. Андагы тарихи һәм истәлекле урыннар сезгә ошар дип уйлыйм. Туристларга шулай ук борынгы Болгарга, Раифа монастырена экскурсияләр тәкъдим ителә.
**Клиент**: Яхшы, аңладым.  Миңа дустым белән киңәшләшергә кирәк. Аның чит илгә барасы килә.
**Хезмәткәр**: Чит илгә бару өчен дә, юлламаны алдан алып кую файдалырак. Алай эшләсәгез, юллама арзанрак була. Әйдәгез, июль аенда нинди турлар барлыгын карап алыйк. Сезне  Европа илләре кызыксындырамы, әллә көнчыгыш илләренә барасыгыз киләме?
**Клиент**: Минем Европаның кайбер илләрендә булганым бар инде. Мәсәлән, Швециядә, Даниядә, Финляндиядә.
**Хезмәткәр**:  Матур урыннарда булгансыз икән. Быел мин сезгә Чехиягә барырга тәкъдим итәм. Борынгы Прагада булу, аның истәлекле урыннарын карау күп туристларда яхшы хисләр, онытылмас хатирәләр калдыра. Безнең агентлыкның сайтына кереп, сез әлеге фикерләр белән таныша аласыз.

**Клиент**: Сезнең белән килешәм. Минем дә бу турыда күп ишеткәнем бар. Берничә танышым бу илгә сәяхәткә барды инде.
**Хезмәткәр**: Барлык мәгълүматны тагын бер тапкыр сайттан карый аласыз. Ләкин заказ бирүне озакка сузмагыз, чөнки бәяләр көн саен арта. Шушы атнада юлламаны сатып алсагыз, 15 % ташлама булачак. Кая барасын хәл иттегезме инде? Әллә дустыгыз белән хәл итеп бетерәсезме?
**Клиент**: Аның белән сөйләшкәч килермен. Рәхмәт Сезгә барысы өчен дә.
**Хезмәткәр**: Безнең агентлыкка мөрәҗәгать итүегез өчен Сезгә рәхмәт! Мин сезгә күңелле сәяхәт телим! Сау булыгыз!
**Клиент**: Сау булыгыз!

**Бирем.**
Сез мәктәп китапханәсенә килгән укучы ролен башкарасыз һәм китапханәче белән әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында
- алырга теләгән китабыгыз турында әйтегез;
- бу язучының башка әсәрләре турында белешегез;
- яшьләр арасында популяр булган китаплар турында кызыксыныгыз;
- татар язучыларының иҗаты турында фикерләрегезне белдерегез;
- әдәбият белән кызыксынуыгызны ассызыклагыз.

## КИТАПХАНӘДӘ

**Үрнәк диалог.**

**Укучы**: Керергә ярыймы? Хәерле көн!
**Китапханәче**: Рәхим итегез! Хәерле көн!
**Укучы**: Безгә татар әдәбиятыннан Мөхәммәт Мәһдиевнең “Без – кырык беренче ел балалары” повестен укырга куштылар. Сездән бу китапны алырга буламы?
**Китапханәче**: Әйе, әлбәттә, хәзер табам. Башка әсәрләре дә кирәк түгелме?
**Укучы**: Укытучы шушы әсәр турында гына әйтте. Ә аның тагын нинди әсәрләре бар? Алар белән дә танышу миңа кызык булыр иде. Минем бу язучы турында Интернеттан укыганым бар.
**Китапханәче**: Аның әсәрләре шактый күп. Иң танылганнары - “Торналар төшкән җирдә”, “Ут чәчәк”, “Кеше китә – җыры кала” һ.б.
**Укучы**: Күп икән. Мин сугыш турында да, яшьләр турында да укырга яратам. Ә сез миңа кайсыларын укырга тәкъдим итәрсез?
**Китапханәче**: Язучының һәр әсәре – тормыш турында зур ачыш. Олы яшьтәге укучылар да, яшьләр дә аның әсәрләрен бик яратып укыйлар.
**Укучы**: Алайса “Торналар төшкән җирдә” исемле әсәрен дә алыйм әле. “Без – кырык беренче ел балалары” повестен укып чыккач, икенчесен дә укырга вакыт

табарга тырышырмын. Без дәресләрдә танылган татар язучыларының иҗаты белән танышабыз. Алар арасында Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый, Гомәр Бәширов һ.б. Татар шагыйрьләрен дә беләм әле. Без Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Роберт Миңнуллин шигырьләрен яттан өйрәндек.
**Китапханәче**: Менә күпме беләсез. Димәк, сез әдәбият белән кызыксынасыз.
**Укучы**: Безнең гаиләдә барысы да укырга ярата. Мин дә кечкенәдән төрле әкиятләр укырга яраттым. Аннары маҗаралар һәм детективлар белән мавыктым. Әнием һәрвакыт миңа яңа китаплар ала иде. Ә хәзер мин электрон китапханәдән файдаланам. Бу бик уңайлы.
**Китиапханәче**: Әйе, хәзер уку өчен мөмкинлекләр бик күп. Өйдән чыкмыйча, теләсә кайсы китапны табып була.
**Укучы**: Ә менә күпчелек яшьләр Интернетны китап уку өчен түгел, ә уеннар уйнау өчен кулланалар. Күпме вакытларын уйнап үткәрәләр. Шул вакыт эчендә зур романнар укырга мөмкин. Ләкин аларны китап кызыксындырмый.
**Китапханәче**: Сезнең белән килешәм. Кечкенәдән балаларны китап укырга өйрәтергә кирәк.
**Укучы**: Рәхмәт Сезгә!
**Китапханәче**: Сезгә дә рәхмәт шундый укымышлы булуыгыз өчен. Китап яхшы киңәшчегез булсын.
**Укучы**: Сау булыгыз!
**Китапханәче**: Сау булыгыз!

**Бирем.**

Сез татар теленнән халыкара олимпиадада катнашу кагыйдәләре турында укытучыгыз белән әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында:
- олимпиада үткәрү турындагы мәгълүмат белән кызыксыныгыз;
- үзегез катнашкан башка олимпиадалар турында мәгълүмат җиткерегез;
- башка еллардагы олимпиада сораулары белән кызыксыныгыз;
- олимпиаданың үткәрелү вакыты турында сорагыз;
- олимпиадада катнаша алу-алмавыгыз турында мәгълүмат бирегез.

ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДАДА КАТНАШУ

**Үрнәк диалог.**

**Укучы**: Исәнмесез!
**Укытучы**: Хәерле көн!

**Укучы**: Гафу итегез, Сез дәрестә татар теленнән халыкара олимпиада үткәрелү турында әйткән идегез. Бу хакта тулырак мәгълүматны каян алып була, әйтмәссезме? Бәлки Сездә мәгълүмат хаты да бардыр?
**Укытучы**: Әйе, әлбәттә. Бу хакта Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтыннан укый аласыз. Кызыксынсагыз, мин Сезнең электрон почтагызга мәгълүмат хатын да җибәрермен.
**Укучы**: Бик зур рәхмәт Сезгә. Минем математикадан, инглиз теленнән олимпиадаларда катнашканым бар. Быел, мөмкин булса, татар теленнән халыкара олимпиадада да катнашыр идем. Ничек уйлыйсыз, минем мөмкинлекләрем бармы?
**Укытучы**: Әйе, бар дип уйлыйм. Теләк һәм тырышлык кына кирәк. Теләк булса, бар нәрсәгә дә ирешеп була.
**Укучы**: Мин телим һәм тырышырмын. Ә башка елларда татар теленнән халыкара олимпиада сораулары катлаулы була идеме? Анда грамматиканы гына белү кирәкме?
**Укытучы**: Мин Сезгә үткән елгы олимпиада сорауларын да җибәрермен. Үзегез бәяләрсез: авырмы, җиңелме? Олимпиадада грамматик белемнәр генә түгел, тапкырлык, зирәклек тә сынала.
**Укучы:** Әйе, аңладым. Бу инглиз теленнән үткәрелгән олимпиада кебектер. Анда да башваткычлар, лингвистик табышмаклар һәм билгеле бер темага очерк язу биреме дә бар иде.
**Укытучы**: Әйе, гадәттә, иҗади бирем дә була.
**Укучы**: Гафу итегез, ә татар әдәбиятыннан сораулар буламы? Грамматик кагыйдәләрне яхшы белсәм дә, кызганычка каршы, мин татар әдипләренең иҗатын начар беләм.
**Укытучы**: Олимпиада татар теленнән үткәрелә. Нигездә, тел белү дәрәҗәсе тикшерелә. Әмма әдәбият, мәдәният, тарих белән бәйле сораулар да булырга мөмкин.
**Укучы**: Димәк, татар әдәбиятын да укырга кирәк булачак... Ә Сез әйтә алмассызмы: олимпиаданың беренчы туры кайчан була?
**Укытучы**: Татар теленнән халыкара олимпиаданың беренче туры декабрьдә була. Җиңүчеләр икенче турга үтәләр, һәм алар апрель аенда Казанда җыелалар.
**Укучы**: Кызык. Чит илләрдән дә яшьләр була дип ишеткән идем. Бу дөресме?
**Укытучы:** Була, әлбәттә. Икенче халыкара олимпиадада япон студенты хәтта Гран-при яулады.
**Укучы**: Мәгълүмат өчен, зур рәхмәт! Мин олимпиадага, һичшиксез, әзерләнәчәкмен. Сорауларым булса, Сезгә мөрәҗәгать итәрмен. Сау булыгыз!
**Укытучы**: Сау булыгыз!

**Бирем.**

Сез милли бәйрәмнәрне үткәрү турында чит илдән килгән танышыгыз белән әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында

- аның татар милли бәйрәме – Сабан туенда – булу-булмавы белән кызыксыныгыз;
- аның илендә нинди милли бәйрәмнәр барлыгын белегез;
- татар милли бәйрәмнәрендәге төп чаралар турында мәгълүмат бирегез;
- танышыгызның нинди татар милли бәйрәмендә булырга теләве турында сорагыз;
- бәйрәмгә бергә барырга тәкъдим ясагыз.

## МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘР

**Үрнәк диалог.**

**Укучы**: Хәерле көн!
**Таныш**: Сәлам! Хәерле көн!
**Укучы**:Син нинди китап укып утырасың?
**Таныш**: Татар милли бәйрәмнәре турында китап укыйм.
**Укучы**: Сиңа ошыймы? Үзеңнең кайсы милли бәйрәмдә катнашканың бар?
**Таныш**: Китап бик кызыклы. Ләкин минем татар милли бәйрәмен күргәнем юк.
**Укучы**: Синең Сабан туенда да булганың юкмы? Сабан туе хәзер бик күп чит илләрдә дә үткәрелә.
**Таныш**: Әйе, ишеткәнем бар, ләкин күргәнем юк.
**Укучы**: Ә синең Сабан туен күрәсең киләме? Анда бик кызык була. Татар милли бәйрәмнәрендә кешеләр җыйрлыйлар, бииләр, аркан тартышу, баганага мену, чүлмәк вату, капчык киеп йөгерү кебек уеннарда катнашалар. Анда ат чабышы, көрәш буенча да ярышлар үткәрәләр. Халык мәйданда рәхәтләнеп күңел ача.
**Таныш**: Минем Сабан туен күрәсем килә. Быел җәй мин Казанда булам. Сабан туен карарга телим.
**Укучы**: Бик яхшы. Әйдә, Сабан туена бергә барабыз. Мин сиңа экскурсовод булырмын.
**Таныш**: Бик рәхәтләнеп. Килештек. Ә сездә чыннан да Нәүрүз, Сөмбелә бәйрәмнәре дә үткәреләме? Китапта шулай язылган.
**Укучы**: Кызганычка каршы, хәзер сирәк үткәрелә инде. Элек әби-бабаларыбыз үткәргәннәр. Ә Америкада милли бәйрәмнәрне билгеләп үтәләрме?
**Таныш**: Америка - күпмилләтле дәүләт. Анда бар халык өчен уртак милли бәйрәмнәр юк, шуңа күрә һәр халык үз милли бәйрәмнәрен үткәрә. Минем гаиләмдә Рәхмәт көнен, Изге Патрик көнен бәйрәм итәләр.
**Укучы**: Әйе, минем укыганым бар. Татарлар милли бәйрәмнәрдә тәмле ризыклар пешерәләр һәм дусларын, туганнарын, танышларын сыйлыйлар. Ә Сез бәйрәмнәрдә нишлисез?

**Таныш**: Бергә җыелабыз, Америка футболы карыйбыз, төрле ризыклар ашыйбыз. Аралашабыз, күңел ачабыз.
**Укучы**: Мәгълүмат өчен рәхмәт сиңа! Димәк, быел Сабан туена бергә барачакбыз. Әлегә сау булып тор, мин дә китапханәдән дәрес әзерләү өчен кирәкле китапларымны алыйм әле.
**Таныш**: Яхшы. Сау бул!

**Бирем.**

Сез, туганнан туган сеңлегез белән очрашып, һөнәр сайлау турында әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында
- җәйге ялда сеңлегезнең нишләргә теләве белән кызыксыныгыз;
- хәзерге вакытта кирәкле һөнәрләр турында мәгълүмат бирегез;
- аңа нинди һөнәрләр ошавы турында сорагыз;
- үзегезгә охшаган һөнәрләр турында әйтегезз, әмма әлегә һөнәрне төгәл сайламавыгызны җиткерегез;
- җәен бергә эшләргә тәкъдим итегез.

## ЭШ ЭЗЛӘҮ

**Үрнәк диалог.**

**Укучы**: Хәерле көн, сеңлем! Син белдерүләр тактасы янында нишлисең?
**Сеңел**: Хәерле көн! Тиздән җәйге ял башлана. Мин ял вакытында эшләргә телим. Монда укучылар өчен вакытлыча эш урыннары тәкъдим итәләр, шуларны карыйм.
**Укучы**: Кызык. Ә нинди эш урыннары тәкъдим итәләр?
**Сеңел**: Чәчәк утыртучылар, промоутерлар, җыештыручылар кирәк икән.
**Укучы**: Син нинди эш сайладың инде? Сиңа нинди һөнәрләр ошый?
**Сеңел**: Сайламадым әле. Минем киләчәктә медицина хезмәткәре буласым килә, ләкин монда андый эшләр күрмим.
**Укучы**: Миңа да табиб һөнәре бик ошый. Хәзерге вакытта яхшы табиблар, информатика белгечләре, төзүчеләр, проект эшләре белән шөгыльләнүче хезмәткәрләр кирәклеген беләм. Миңа бу һөнәрләр барысы да кызыклы, шуңа күрә кайсын сайларга да белмим әле. Киләсе елга кадәр сайларга кирәк инде. Ә син белдерүләрне тагын кайдан эзләдең?
**Сеңел**: Әлегә менә бу белдерүләр тактасыннан гына.
**Укучы**: Минемчә, Интернетта алар күбрәктер. Аннан карарга кирәк. Бәлки без бергә эшләрбез. Ләкин мин быел 9 нчы сыйныфны тәмамлыйм. Июньдә әле имтиханнар тапшырасым бар. Аннары безнең чыгарылыш кичәсе була. Син ялга чыккач, бераз ял итсәң, без бергә эшкә барыр идек.

**Сеңел**: Яхшы. Мин риза. Ләкин эш урынын алдан ачыкларга кирәк, аннары булмаска мөмкин.
**Укучы**: Әлбәттә, алдан эзлибез. Син дә кара, мин дә эзләрмен. Тапкач, бер-беребезгә хәбәр итәрбез. Әти-әниләр белән дә киңәшләшергә кирәк.
**Сеңел**: Яхшы. Ә син хәзер кая барасың?
**Укучы**: Мәктәпкә, консультациягә. Өч көннән без математикадан имтихан тапшырабыз. Әлегә шуңа әзерләнәм. Гафу ит, хәзер тоткарлана алмыйм. Соңга калуым бар.
**Сеңел**: Ярый, сау бул! Имтиханнарыңны уңышлы тапшыр!
**Укучы**: Сау бул! Әти-әниеңә сәлам әйт.
**Сеңел**: Яхшы, әйтермен. Уңышлар сиңа!
**Укучы**: Рәхмәт!

**Бирем.**
Сез дустыгыз белән табигатькә ялга чыгарга җыенасыз. Телефоннан шалтыратып, шул турыда сөйләшегез. Сөйләшү барышында
- үзең белән алырга кирәкле әйберләр турында әйтегез;
- ял вакытында эшлисе эшләрегез турында белешегез;
- дусларыгыздан кемнәрне чакыруыгыз турында кызыксыныгыз;
- табигатьне пычратмас өчен, кирәкле чаралар турында фикерләрегезне белдерегез;
- дустыгыздан иртән сезне уятуын сорагыз.

## ТАБИГАТЬКӘ ЧЫГУ

**Үрнәк диалог.**

**Укучы**: Алло! Хәерле көн!
**Дус**: Әйе. Сәлам!
**Укучы**: Дустым, безнең планнар килешенгәнчә каламы? Без иртәгә табигатькә ял итәргә барабызмы?
**Дус**: Әйе, әлбәттә.
**Укучы**: Мин кичә дуслар белән күрешмәдем, шуңа күрә үзем белән нәрсәләр алырга кирәклеген төгәл белмим. Дустым, бүлешкән әйберләр элеккечә каламы? Мин шырпы, өстәл җәймәсе, 5 литр чиста су һәм ипи алып килергә тиеш. Шулар гынамы?
**Дус**: Минемчә, әйе. Кармак алырга онытма.
**Укучы**: Хәтерлим. Без анда балык тотатачакбыз, уха пешерәчәкбез. Аннары нишлибез?

**Дус**: Дуслар волейбол һәм футбол туплары алалар, димәк, волейбол, футбол уйнаячакбыз. Алмаз теннис ракеткалары алып киләчәк. Әлбәттә, су коеначакбыз.

**Укучы**: Яхшы. Минемчә, без яхшы ял итәчәкбез. Ә кемнәр барачак? Төркемебездән барысы да бара алалармы?

**Дус**: Без 12 кеше булачакбыз. Алия белән Саша килә алмыйлар. Алиянең әти-әнисенә ярдәм итәсе бар, ә Саша иртәгә Мәскәүгә китә.

**Укучы**: Кызганыч, алар да булса, күңеллерәк булыр иде. Дустым, гафу ит, сорарга онытканмын: сез чүп салу өчен махсус пакетлар алу турында сөйләштегезме?

**Дус**: Юк, онытканбыз.

**Укучы**: Ярый, үзем алырмын. Табигатьне пычратмас өчен, чүпләрне җыеп калдырырга кирәк бит. Минемчә, без бара торган аланда чүпләр салу өчен махсус урын бар. Ләкин аларны пакетка салып калдырырга кирәк. Дустым, сиңа тагын бер үтенечем бар иде.

**Дус**: Тыңлыйм.

**Укучы**: Гадәттә мин шимбә һәм якшәмбе көннәрендә озак йоклыйм. Иртә тормыйм. Иртәгә дә йоклап калырмын дип куркам. Мине иртән шалтыратып уята алмассыңмы?

**Дус**: Ярый. Сәгать ничәдә уятырга?

**Укучы**: Җидедә.

Дус: Яхшы, уятырмын.

Укучы: Зур рәхмәт! Сау бул! Иртәгәгә кадәр.

**Дус**: Сау бул!

**Бирем.**

Сез шәһәр транспортындагы пассажир ролен башкарасыз һәм кондуктор белән әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында
- бу автобусның сезгә кирәкле тукталышка кадәр бару-бармавын сорагыз;
- сез барасы урынның кайда урнашуын аңлатыгыз;
- кирәкле урынга кадәр ничек барырга кирәклеген ачыклагыз;
- бу маршрут буенча нинди транспорт белән кире кайтып булуы турында кызыксыныгыз;
- кондукторның тәкъдимен кабул итегез яки кире кагыгыз.

## ШӘҺӘР ТРАНСПОРТЫНДА

**Үрнәк диалог.**

**Укучы**: Гафу итегез, Сезгә мөрәҗәгать итәргә мөмкинме? Бу автобус Сәлимҗанов урамына кадәр барамы?

**Кондуктор**: Әйе, бара. Сезгә нинди тукталыш кирәк?
**Укучы**: Гафу итегез, әмма мин тукталышның исемен белмим. Миңа “Мирас” яшүсмерләр клубы кирәк иде. Ул Сәлимҗанов урамында, 24 нче йортта урнашкан.
**Кондуктор**: Кызганычка каршы, мин бу клубны белмим. Аның янында тагын нинди оешмалар бар?
**Укучы**: Мин төгәл генә белмим, ләкин “Эдельвейс” кибете, “Лик” мода студиясе бар дип әйттеләр. Каршында 12 нче балалар бакчасы урнашкан.
**Кондуктор**: Аңладым. Кызганычка каршы, без Сәлимҗанов урамындагы 4 нче йортка кадәр генә барабыз, аннары сулга борылабыз. Сезгә “Кинотеатр” тукталышында төшәргә кирәк булачак.
**Укучы**: Аннары ничек барырга?
**Кондуктор**: Ике тукталыш җәяү барырга мөмкин, яки 2 нче троллейбуска утырыгыз.
**Укучы:** Гафу итегез, ә кире кайтканда, шәһәр үзәгенә кадәр туры автобус йөриме? Әйтә алмыйсызмы?
**Кондуктор**: Әйе, йөри. 28 нче яки 54 нче автобуслар белән кайта аласыз. 2 нче троллейбус та шәһәр үзәгенә кадәр бара.
**Укучы**: Ярдәм итүегез өчен зур рәхмәт сезгә!
**Кондуктор**: Яхшы. Сез хәзер безнең автобуста барачаксызмы соң? Барсагыз, утырыгыз. Хәзер автобус кузгалачак.
**Укучы**: Әйе, әлбәттә, барачакмын. Сез миңа кайсы тукталышта төшәргә кирәклеген искәртегезче. Мин беренче тапкыр барам, юлны начар беләм. Озак барырга кирәкме?
**Кондуктор**: Яхшы, әйтермен. Сезгә 5 тукталыштан соң гына төшәргә кирәк булачак.
**Укучы**: Барысы өчен дә рәхмәт Сезгә.

**Бирем.**
Сез урамда элеккеге сыйныфташыгызны очраттыгыз. Ул да 9 нчы сыйныфта тапшырылачак имтиханнарга әзерләнә. Аның белән әңгәмә корасыз. Сөйләшү барышында
- аның хәзер кайда укуы турында сорагыз;
- чыгарылыш имтиханнарына ничек әзерләнүе турында белешегез;
- киләчәктә укуыгызны кайда дәвам итәчәгегез турында мәгълүмат бирегез;
- имтиханга әзерләнү турында фикерләрегезне белдерегез;
- ашыгуыгыз һәм озак сөйләшә алмавыгыз өчен гафу үтенегез.

ИМТИХАННАРГА ӘЗЕРЛӘНҮ

**Үрнәк диалог.**

**Укучы**: Сәлим /Сәлимә, бу синме? Исәнме!
**Сыйныфташ**: Сәлам! Хәерле көн!
**Укучы**: Менә нинди көтелмәгән очрашу! Син кая барасың? Биредә яшисеңме? Күптән очрашканыбыз юк бит инде...
**Сыйныфташ**: Әйе, 2 ел чамасы очрашмадык. Мин дустыма барам. Без имтиханнарга бергә әзерләнәбез.
**Укучы**: Әйе, без дә тиздән имтиханнар тапшырабыз. Ә син хәзер кайда укыйсың?
**Сыйныфташ**: 4 нче гимназиядә. Ә син шул ук мәктәптәме?
**Укучы**: Әйе, шунда ук. Сыйныф җитәкчебез дә – Мария Александровна. Син аны беләсең бит. Без Самат, Гүзәл, Миша белән бер сыйныфта укыйбыз. Хәзер имтиханнарга әзерләнәбез. Син имтиханга репетитор белән әзерләнәсеңме?
**Сыйныфташ**: Юк, без сыйныфташлар белән бергә шөгыльләнәбез. Төрле сорауларны бүлеп алабыз да бер-беребезгә аңлатабыз.
**Укучы**: Җавапларны кайдан аласыз? Интернеттанмы, әллә укытучыдан сорыйсызмы?
**Сыйныфташ**: Интернеттан да карыйбыз, укытучыдан да сорыйбыз, күп китаплар, энциклопедияләр дә укыйбыз.
**Укучы**: Әйе, бергә әзерләнү яхшырак һәм җиңелрәк. Ә син киләчәктә кем булырга телисең? Укуыңны кайда дәвам итәчәксең? Техникумга китәсеңме, әллә 10 нчы сыйныфка барасыңмы?
**Сыйныфташ**: Үз мәктәбебездә 10 нчы сыйныфка барам.
**Укучы**: Мин дә 10 нчы сыйныфта укыячакмын. 11 нче сыйныфны тәмамлагач, университетка укырга керергә телим. Минем химик буласым килә. Химия фәне бик кызыклы бит. Менә хәзер дә яшь химиклар клубына барам. Ул мәктәбебез каршында эшли. Анда төрле тәҗрибәләр ясарга өйрәтәләр, кызыклы китаплар тәкъдим итәләр. Химиядән имтиханга әзерләнү өчен дә бик файдалы. Хәзер сәгать ничә?
**Сыйныфташ**: 10 минуттан биш тула
**Укучы**: О-О! Гафу ит, мин ашыгам. Клубка соңга калам. Башка вакытта очрашып сөйләшик әле. Син миңа шалтырат. Минем телефон номеры синдә бармы? Ул үзгәрмәде.
**Сыйныфташ**: Кызганычка каршы, юк шул.
**Укучы**: Әйдә. Яз. 8-919-632-24-81. Шалтырат. Имтиханнар турында да сөйләшербез. Сау бул!
**Сыйныфташ**: Сау бул! Дусларга сәлам әйт!

## СҮЗЛЕКЧӘ

**авырлыклар кичерергә** — преодолевать трудности
**агулый** — отравляет
**аерма** — различие
**акланырга** — быть оправданным
**акча сугарга** — чеканить деньги
**алан** — поляна
**алгы бүлмә** — прихожая
**алманча** — по-немецки
**аңлатмалы сүзлек** — толковый
**аралашырга** — общаться
**аралашырга** — общаться
**арка** — спина
**аркан тартышу** — перетягивание каната
**ачкыч** — ключ
**ачыш** — открытие
**әверелергә** — превращаться
**әдәбият** — литература
**әйләнә-тирә мохит** — окружающая среда
**әһәмияте ягыннан** — по значимости
**басма табак** — печатный лист
**багланышлар** — связи
**баета -** обогащает
**баскыч** — *здесь*: ступенька
**басма** — издание
**басма** — издание
**башкарма** — исполнительный
**«Башмагым»** — «Башмачки»
**БДБ илләре** — страны СНГ
**белгеч** — специалист
**беләзек** — браслет
**бәллүр** — хрустальный
**бергәләп** — вместе
**бил** — поясница
**билге** — знак, символ
**билгеләп үтәргә** – отметить
**билгеләргә** — определять
**боерык** — приказ
**буыннан буынга** — из поколения в поколение
**буярга** — красить
**вакыйга** — событие
**васыять** — завещание
**вәкаләтле вәкиллек** — полномочное представительство
**вәкил** — представитель
**гадел** — справедливый
**гадәттә** — обычно
**гамәлгә кертергә** — претворять в жизнь
**гарәпчә** — по-арабски
**горурлык** — гордость
**гөрләвек** — ручей
**гыйбрәтле хәл** — поучительное событие
**гыйлем йортлары** — учебные заведения
**даими** — постоянно
**дәвер** — период
**дивар** — стена
**дин** — религия
**дөньяви** — светский
**дөньяга килергә** — родиться
**дулкын** — волна
**дүрткырлы** — четырехгранный
**егарга** — повалить
**егылырга** — упасть
**еш** — часто
**җанлылык** — оживление
**җәмәгатьчелек** — общественность
**җәннәт** — рай
**җилкән** — парус
**җилләтергә** — проветривать
**җитди** — серьезно, серьезный
**җитәкче** — руководитель

**җитештерелә** — производится
**җөмлә** — предложение
**җыентык** — сборник
**җыештырырга** — убирать
**зарарлана** — повреждается
**зиндан** — тюрьма
**Зөя** — Свияга
**игенчелек** — земледелие
**идарә** — управление
**идарә** — управление
**иҗтимагый** — общественный
**изге урын** — святилище
**иксез-чиксез** — несметный
**имгәнергә** — искалечиться
**имән капка** — дубовые ворота
**инану** — вероисповедание
**иркен** — просторный
**исәпләнә** — насчитывается
**истә тотарга** — помнить
**истәлекләр** — воспоминания
**йогынты ясарга** — оказать влияние
**йомгак ясарга** — подводить итог
**йөк** — груз
**кабер** — могила
**канәгать калырга** — оставаться довольным
**катлам-катлам** — пластами // слоями
**кабиләләр** — племена
**кагыйдә** — правило
**кадерләп** — бережно
**каен тузы** — береста
**кайгыртырга** — беспокоиться
**кайгыртырга** — заботиться
**калкан** — щит
**камил белергә -** знать в совершенстве
**капка** — ворота
**капчык** — мешок
**каравыл манарасы** — смотровая башня
**карчыга** — ястреб
**катнаш** — смешанный
**«Качкын»** — «Беглец»
**кашкарый** — астра
**келәм** — ковер
**кәнәфи** — кресло
**кертелә** — ввозится
**килешү** — соглашение
**кимсетү** — унижение
**киң күңелле** — добродушный
**киңәшмә** — совещание
**киңәшмә** — совещание
**кисек** — усеченный
**китап саклагыч** — книгохранилище
**кичә** — вечер
**киштә** — полка
**корал** — инструмент
**көймә** — лодка
**көндәш** — соперник
**көнкүреш** — быт
**көрәштәш** — соратник
**көрәштәш** — соратник
**көтүче** — пастух
**көч** — сила
**куаклык** — кустарник
**күзәтү** — наблюдение
**күк күкри** — гром гремит
**кулга алырга** — арестовать
**күмәргә, капларга** — покрывать
**күчәргә** — переехать
**кушуы буенча** — по поручению
**кушуы буенча** — по поручению
**кушылдык** — приток
**кызыксынырга** — интересоваться
**кызынырга** — загорать
**кыллы** — струнный
**кылырга** — делать
**лаек булырга** — быть достойным
**мавыгырга** — увлекаться
**матдә** — вещество
**махсус** — специальный
**махсус** — специальный

**мәгарә** — пещера
**мәгълүмат** — информация
**мәгълүмат** — информация
**мәгънә** — значение
**мәдәният** — культура
**мәҗбүри** — обязательный
**мәһабәт** — величественный
**мәңгелек** — вечность
**мәркәз** — столица
**мәшһүр** — знаменитый
**мизгел** — мгновение
**мирас** — наследие
**моң** — мелодия
**мөгаллим** — педагог
**мөгезле эре терлек** — крупный рогатый скот
**мөлаем** — обаятельный
**мөнәсәбәт** — отношение
**мөрәҗәгать итәргә** — обращаться
**мөхәррир** — редактор
**муен** — шея
**нахак яла** — ложное обвинение
**нәшер итәргә** — издавать
**нибары** — всего лишь,
**нигез салучы** — основоположник
**ныгытма** — сооружение
**ныгытырга** — укреплять
**нык** — сильный
**омтылу** — стремление
**омтылыш** — стремление
**оста** — умелый
**остаз** — наставник
**остаханә** — мастерская
**өлеш** — часть
**өлеш кертергә** — внести вклад
**өлеш кертергә** — внести вклад
**өмет** — надежда
**пәрдә** — занавеска
**пулат** — дворец
**рәис** — председатель
**рух** — дух
**рухани** — духовный
**рухи** — духовный
**сарыф итәргә** — тратить
**сазлык** — болото
**салават күпере** — радуга
**салым** — налог
**сан буенча** — по численности
**сандугач** — соловей
**сәед** — сеид (почетный титул мусульман)
**сәйлән** — бисер
**сәнгать** — искусство
**серле** — таинственный
**сәясәтче** — политик
**сихерле** — волшебный
словарь
**сокланырга** — восхищаться
**сөлге** — полотенце
**су китерергә** — приносить воду
**су сибәргә** — поливать
**сүз** — слово
**сын** — скульптура
**тармак** — отрасль
**табын** — праздничный стол
**таләп** — требование
**таң калдырырлык** — восхитительный
**тантаналы** — торжественный
**тантаналы төстә** — торжественно
**танылу** — признание
**таркалганнан соң** — после распада
**тармак** — отрасль
**тартышу** — сопротивление
**тасвирларга** — описывать
**тасма** — лента
**тастымал** — полотенце
**тәҗрибәле** — опытный
**тәкә** — баран
**текә** — крутой
**тел белеме** — языкознание
**телче** — языковед
**тәнкыйть** — критика
**тәнкыйтьләргә** — критиковать

**тәрәзә төбе** — подоконник
**тәхет** — трон
**тәшкил итәргә** — составлять
**тәэсир** — впечатление
**тикшеренү** — исследование
**тимерче** — кузнец
**тиң** — равносильно
**тиңдәш** — подобный
**торгызырга** — восстанавливать
**тормыш** — жизнь
**төбәк** — регион
**төгәлләү** — завершение
**төзелеш нигезләре** — основы устройства
**төркем** — группа
**төрки телләр** — тюркские языки
**туган якны өйрәнүче** — краевед
**түзә алмаслык** — нестерпимый
**тукланырга** — питаться
**тукучылык** — ткачество
**түләүле** — платный
**тулысынча** — полностью
**тупланма** — коллекция
**тупларга** — объединять
**тынгысыз** – беспокойный
**тынгысыз** — беспокойный
**тыш** — кроме
**уңайлы** — удобный
**уңыш казанырга** — прославиться
**уңыш** — урожай
**урта хәлле** — середняк
**уртак** — общий
**урын өстендә** — прикован к постели
**утырыш** — заседание
**үзенчәлек** — особенность
**үзешчән** — самодеятельный
**үзләштерергә –** усвоить
**үлем җәзасы** — смертная казнь
**үлемсез** — бессмертный
**үрчетергә** — разводить
**үсеш** — развитие
**үсеш** — развитие
**үсеш** — развитие
**үтенеч** — просьба
**үтәргә** — проходить
**үткен** — острый
**үткәрергә** — проводить
**фаҗигале** — трагический
**фатиха** — благословение
**фәкыйрьлек** — бедность
**фән эшлеклеләре** — научные деятели
**фәнни-сәнәгый** — научно-промышленный
**фидакарь** — самоотверженный
**фикердәш** — единомышленник
**фикерләргә** — мыслить
**хакимият** — власть
**хакимият** — администрация
**халыкара** — международный
**хәзинәләр** — ценности
**хезмәткәр** — сотрудник
**хезмәттәшлек** — сотрудничество
**хәрби әсир** — военнопленный
**хәрби әсирләр** — военнопленные
**хәтерләргә** — помнить
**хәтта** — даже
**хис** — чувство
**хисапчы** — бухгалтер
**хокук** — право
**хөкем итәргә** — приговорить
**хөкүмәт** — правительство
**хуҗабикә** — домохозяйка
**һәлак булырга** — погибнуть
**һичшиксез** — несомненно
**чигүле** — вышитый
**чикләнергә** — ограничиться
**чиратлашып** — по очереди
**чиркәү кирәк-яраклары** — церковная утварь
**читтән торып уку бүлеге** — заочное отделение
**чор** — период
**чуен** — сталь

**чүкеч** — молот
**чүлмәк вату** — разбивание горшка
**чүп утарга** — полоть
**чыгарыла** — вывозится
**чыгыш ясарга** — выступать
**чын мәгънәсендә** — по-настоящему
**чыныктыру** — закаливание
**шәмдәл** — подсвечник
**шәһәр төрендәге бистә** — поселок городского типа
**Шәрык** — Восток
**шәхес** — личность
**шәхси ирек** — личная свобода
**шифалы** — целебный
**шома колга** — гладкий столб
**шуңа да карамастан** — несмотря на это
**ылыслы** — хвойный
**ысул** — способ
**ышанычлы** — доверительный
**энҗе** — жемчуг
**эшмәкәр** — бизнесмен
**эшчәнлек** — деятельность
**югары бәя** — высокая оценка
**юк итәргә** — уничтожить
**юкә** — липа
**юл** — *здесь*: строка
**юыну бүлмәсе** — ванная
**юыну әйберләре** — ванные принадлежности
**яктыртырга** — освещать
**ялкын** — пламя
**ялкынлы** — пламенный
**янгын** — пожар
**яр** — берег
**яшен** — молния
**яшерен** — подпольный